*— Була. Фабрикада эшләнгән* (фабричные).

*41. — Кибетләрнең исемнәре* (названия) *татарча ничек була?*

— *«Киемнәр»* («Одежда»), *«Өс киемнәре»* («Верхняя одежда»), *«Баш киемнәре»* («Головные уборы»), *«Аяк киемнәре»* («Обувь»), *«Промтоварлар»* (Промтовары»), *«ХуҖалык товарлары»* («Хозяйственные товары»), *«Балалар дӨньясы»* («Детский мир»).

ˈ**адание**. Отвечайте на вопросы.

1) — Бу куртка ничә сум?

— -------------------------------.

2) ٿост|м ничә сум?

— -----------------------.

3) ٿүлмәк ни хак?

— -----------------.

4) — Сездә пальтолар бармы?

— -------------------.

5) — Сездә туннар бармы?

— ---------------------------.

6) — Бу кост|м ми|а ярыймы?

— ----------------------------.

7) — Бу плаѝ ничәнче үлчәм (размер)?

— ----------------------------.

8) — Бу коôтаны күрсәтегез әле.

— ---------------------------.

На прощание вам 3 пословицы.

*Акчаның кҮзе юк* [акъчаның кҮзе йукъ] — У денег глаз нет.

*Аракы керсә, оят качар* [аракъы керсә, ойат къачар] — если приходит водка, стыд убегает.

*Кискән икмәк кире ябышмый* [кискән икмәк кире йабышмый] — отрезанный хлеб обратно не пристанет.

Сау булыгыз! Сезгә уңышлар телим!




# Урок двадцатый

(Егерменче дәрес)

— Исәнмесез, хӨрмәтле дуслар! (Здравствуйте, уважаемые друзья!)

Надеемся, что вы внимательно следите за уроками, усваиваете произношение звуков, отражение их в письме, ведете разговоры на татарском языке, изучаете грамматические правила.

Вы уже окончательно убедились в существовании закона сингармонизма и заметили, что татарские слова или только твердые, или только мягкие. Вы заметили также, что в татарском языке есть особая форма принадлежности, выражаемая аффиксами, которые присоединяются к именам существительным. Узнали, что корень слова в татарском языке не изменяется и к нему друг за другом в определенном порядке «прилепляются» аффиксы. Но, наверное, самым трудным для вас до сих пор являются особые звуки татарского языка, которых нет в русском. Среди гласных это огубленное [а], его мягкая пара — [ә], краткие [ы], [е], [о], [Ө], огубленный мягкий [Ү]. Среди согласных это — [–], [„], [Җ], [ч], [ң], [Һ], гамза (Һәмзә). Очень важно, чтобы вы помнили, что гласные звуки в татарском языке образуют пару: **а-ә, у-Ү, о-Ө, ы-е, ый-и**.

Что касается имен существительных, они имеют формы множественного числа, принадлежности и падежа, аффиксы которых присоединяются к корню или основе в таком порядке. Помните?

*бала-лар-ыбыз-га* *кул-лар-ым-а*
*кҮз-ләр-егез-не* *кӨн-нәр-ең-дә*

Не забыли, конечно, формы вопроса в татарском языке: 1) это вопросительные частицы — **мы/-ме**?; 2) вопросительные местоимения (**кем?, нәрсә? ничек?, кайда?, кая?, кайчан?**); 3) интонация вопроса.

Отрицание оформляется словами «юк», «тҮгел» и аффиксами отрицания — **-ма/-мә** в глаголах. Это вы тоже уже знаете.

*1. — Бу алма.*

*— Юк, бу алма тҮгел, бу айва.*

*2. — Син бар, ә син барма.*

*— Ярар.*

*3. — Сез әйтегез, ә сез әйтмәгез.*

*— Ярый.*

**Задание 1.** Прочитайте текст. Переведите.

*Мин — ЗӨләйха. Минем фамилиям — Сафина. Минем әнием, әтием бар. әниемнең исеме — әминә. әтиемнең исеме — ТаҺир. Алар да — Сафиннар. Минем абыем бар. Аның исеме — Мансур. Аның да фамилиясе — Сафин. Мансур абый — студент. Ул Казан университетында укый. Ул — юридик факультетта икенче курста укый. Минем энем Һәм сеңлем бар. Энемә — 12 яшь. Аның исеме — Тимур. Тимур алтынчы сыйныфта укый. Ул 131 нче мәктәптә укый. Ул яхшы Һәм бик яхшы билгеләренә укый. Сеңлем МиләҮшәгә 10 яшь. Ул татар гимназиясендә укый. Гимназияне ул бик ярата. МиләҮшә бик матур Җырлый. Ул «И туган тел...» Җырын ярата. Мин дә бу Җырны яратам.*

*Минем әнием даруханәдә (аптекада) эшли. әтием — бухгалтер (хисапчы). әтием заводта эшли.*

*Безнең Өйдә әниемнең әнисе — минем әбием яши. Аңа 82 яшь инде. Без аны бик яратабыз. Ул безгә кҮп әкиятләр сӨйли.*

*Безнең гаилә бик дус яши.*

* * *

Сегодня мы продолжаем изучение глагольных времен.

## Прошедшее неочевидное (неопределенное)

Положительный аспект

В татарском языке эта форма времени выражает действие, которое говорящий не видел, а только узнал его результат. Его аффиксы — **-ган/-гән**, — **-кан/-кән**. Почему такие варианты, вы уже знаете. К этим аффиксам добавляются уже другие личные аффиксы. В 3-ем лице ед.числа личный аффикс отсутствует.

***Личные аффиксы***

| **ثи̦о** | **Единственное число** | **Множественное число** |
|---|---|---|
| 1 | -мын/-мен | -быз/-без |
| 2 | -сыћ/-се | -сыз/-сез |
| 3 | — | -нар/-нәр |

**Единственное число**

| | | |
|---|---|---|
| *Мин бар-ган-мын* | *әйт-кән-мен* | (я, оказывается, ходил, сказал) |
| *Син бар-ган-сың* | *әйт-кән-сең* | (ты, оказывается, ходил, сказал) |
| *Ул бар-ган* | *әйт-кән* | (он, оказывается, ходил, сказал) |

**Множественное число**

| | | |
|---|---|---|
| *Без бар-ган-быз* | *әйт-кән-без* | (мы, оказывается, ходили, сказали) |
| *Сез бар-ган-сыз* | *әйт-кән-сез* | (вы, оказывается, ходили, сказали) |
| *Алар бар-ган-нар* | *әйт-кән-нәр* | (они, оказывается, ходили, сказали) |

**Задание 1.** Переведите предложения.

| | |
|---|---|
| *Сез белгәнсез.* | *Сез ашагансыз.* |
| *Алар белгәннәр.* | *Син ашагансың.* |
| *Мин белгәнмен.* | *Ул ашаган.* |
| *Син Җырлагансың.* | *Кәрим әйткән.* |
| *Ул Җырлаган.* | *Сания килгән.* |
| *Мин алганмын.* | *ЗәйтҮнә кайткан.* |

| | |
|---|---|
| *Сез алгансыз.* | *Мансур укыган.* |

## Отрицательный аспект

### Единственное число

| | |
|---|---|
| *Мин бар-ма-ган-мын* | *әйт-мә-гән-мен* |
| *Син бар-ма-ган-сың* | *әйт-мә-гән-сең* |
| *Ул бар-ма-ган* | *әйт-мә-гән* |

### Множественное число

| | |
|---|---|
| *Без бар-ма-ган-быз* | *әйт-мә-гән-без* |
| *Сез бар-ма-ган-сыз* | *әйт-мә-гән-сез* |
| *Алар бар-ма-ган-нар* | *әйт-мә-гән-нәр* |

Эти глагольные формы можно перевести и прошедшим временем совершенного вида.

А теперь эти глагольные формы употребим в диалогах:

1. — *Алманы кем ашаган?*
   — *Бала.*
2. — *Кем кинога барган?*
   — *Кызлар.*
3. — *Безгә кем килгән?*
   — *Галия апа.*
4. — *Сезгә кем хат язган?*
   — *Ринат.*
5. — *Кичә кем Җырлаган?*
   — *ИлҺам Шакиров.*
6. — *Без ничек белгәнбез?*
   — *ГӨлсем апа әйткән.*
7. — *Сез кичә кинога баргансыз икән* (оказывается).
   — *әйе шул.*
   — *Кем белән бардыгыз?*
   — *Балалар белән.*
   — *Кино яхшы булдымы?*
   — *Бик яхшы.*
8. — *Абый килгәнме?*
   — *Юк, килмәгән.*
9. — *Мансур, син белгәнсең — безгә әйтмәгәнсең.*

*— Юк, мин белмәдем.*
*— Белгәнсең шул.*

10\. *— Кичә концертта Фәридә Кудашева Җырлаган.*
*— әйе. Мин дә концертка бардым.*

11\. *— Кичә дәрес булмаган.*
*— әйе. Укытучы юк иде.*

12\. *— МӨнирә, доктор апа килгән, син безгә әйтмәгәнсең.*
*— Гафу итегез, мин гаепле (виновата).*

13\. *— Син безгә килгәнсең икән.*
*— әйе. ә (а) син юк.*
*— Гафу ит, мин концертка бардым.*

Запомните пословицы с этой формой глагола:

*Үзе кунак чакырган, Үзе баланга киткән* [Үзе къунакъ чакъыр„ан, Үзе балаң„а киткән] — Сама позвала гостей, сама ушла за калиной.

*КӨлмә кешедән, борының Өшегән* [кӨлмә кешедән, бороның ӨшӨгән] (букв. Не смейся над другими, у самого нос отморожен). — Прежде, чем смеяться над людьми, посмотри на себя.

*Ашыккан ашка пешкән* [ашыкъкъан ашкъа пешкән] (букв. Кто торопился, обжегся супом). — Поспешишь, людей насмешишь.

Вторая часть нашего занятия посвящается обозначению времени.

**Который час? (Сәгать ничә?)**

Вас часто спрашивают о времени. Когда вы отвечаете, имейте в виду, что порядок слов в татарском предложении часто будет обратным русскому. Слово *сәгать* [сә„әт] обозначает и часы, и время и час.

1\. *— Сәгать ничә?*
*— Ике.*

2\. *— Сәгать ничә?*
*— Ун.*

3\. *— Сәгать ничә?*
*— Тугызынчы ярты.* (Половина девятого)

Когда необходимо сказать, например, «пять минут третьего», порядок слов в отличие от русского будет наоборот; слово ***минута*** сокращается в виде ***минут.***

*1. — Сәгать ничә?*

*— Өченче биш минут.*

*2. — Сәгать ничә?*

*— Бишенче ун минут.*

*3. — Сәгать ничә?*

*— Алтынчы унбиш минут.*

Можно ответить и по-другому:

*1. — Сәгать ничә?*

*— Ике тулып биш минут.*

Дословно это обозначает: Пять минут после того, как наступило два.

*2. — Сәгать ничә?*

*— ДҮрт тулып ун минут.*

Когда стрелки часов перешли за половину, счет времени уже идет по другой форме:

*1. — Сәгать ничә?*

*— Ике туларга егерме Өч минут* (Без двадцати трех минут два).

Это обозначает дословно: До наступления двух часов двадцать три минуты.

*2. — Сәгать ничә?*

*— Өч туларга егерме минут.*

Ответ может быть и таким:

*1. — Сәгать ничә?*

*— Өч минуттан ике тула.*

*(Биш минуттан Өч тула).* Дословно: через три (пять) минуты наступит три.

При этом **тула** (наступает, *букв.* наполняется) может и опускаться:

*1. — Сәгать ничә?*

*— Ике минуттан сигез.*

*2. — Сәгать ничә?*

*— Унсигез минуттан Җиде.*

Обозначение официального времени такое же, как и в русском языке:

*1. — Сәгать ничә?*

*— Ун сәгать сигез минут.* (10.08.)

*2. — Сәгать ничә?*

*— Сигез сәгать егерме Өч минут.* (8.23.)

**Задание 2.** Указанное время в цифрах скажите словами потатарски. Образец:

$7^{00}$ — сәгать Җиде

$7^{30}$ — сигезенче ярты

$7^{10}$ — сигезенче ун минут

$7^{45}$ — сигез туларга 15 минут

Сәгать ничә?

$8^{00}$ — ?
$9^{30}$ — ?
$10^{05}$ — ?
$10^{30}$ — ?
$10^{40}$ — ?
$10^{57}$ — ?
$11^{00}$ — ?
$11^{12}$ — ?
$12^{30}$ — ?
$12^{47}$ — ?
$12^{59}$ — ?
$13^{00}$ — ?
$13^{22}$ — ?
13 — ?
13 — ?

$13^{43}$ — ?
$14^{03}$ — ?
$15^{20}$ — ?
$16^{30}$ — ?
$17^{37}$ — ?
$18^{41}$ — ?
$19^{52}$ — ?
$20^{00}$ — ?
$20^{18}$ — ?
$21^{25}$ — ?
$22^{30}$ — ?
$23^{09}$ — ?
$23^{27}$ — ?
$23^{30}$ — ?
$24^{00}$ — ?

**Задание 3.** Прочитайте по ролям. Переведите.

а) — Сәгать ничә?

— Икенче биш минут.

б) — Сәгать ничә?

— Алтынчы унбиш минут.

в) — Сәгать ничә?

— Өч тулып биш минут.

г) — Сәгать ничә?

— Ун тулып унбиш минут.

д) — Сәгать ничә?

— Сигез тулып егерме минут.

е) — Сәгать ничә?

— Өч туларга биш минут.

ж) — Сәгать ничә?

— ДҮрт туларга ун минут.

з) — Сәгать ничә?

— Җиде туларга ун минут.

и) — Сәгать ничә?

— Унбиш минуттан Җиде тула.

к) — Сәгать ничә?

— Биш минуттан алты тула.

л) — Сәгать ничә?

— Егерме минуттан — Җиде.

м) — Сәгать ничә?

— ТӨнге бер (*букв*. ночное — один).

н) — Сәгать ничә?

— КӨндезге ике (*букв*. дневное — два).

о) — Сәгать ничә?

— Җиде сәгать ун минут.

п) — Сәгать ничә?

— Ун сәгать унике минут.

р) — Сәгать ничә?

— УндҮрт сәгать егерме бер минут.

с) — Сәгать дҮртме?

— Юк, бишенче Җиде минут.

т) — Сәгать алты тулдымы?

— КҮптән инде!

у) — Сәгать ничә?

— Кичәгечә. (Как и вчера.)

ф) — Сәгать ничә?

— Кичәге вакыт. (Вчерашнее время.)

Примечание. *Два последних ответа — шутки, которыми так богата татарская речь.*

**Задание 4.** Ответьте на вопросы:

1. — *Магазин кайчан ачыла?*

   — ...

2. — *Поезд кайчан китә?*

   — ...

3. — *Автобус кайчан килә?*

   — ...

4. — *Теплоход кайчан китə?*
— ...
5. — *Концерт кайчан башлана?*
— ...
6. — *Экзамен кайчан бетə?*
— ...

Запомните слова, связанные со временем:

*кӨн* — день
*тӨн* — ночь
*атна* — неделя
*ай* — месяц; месяц на небе
*ел* — год
*тəҮлек* — сутки
*ярты ел* — полгода
*бҮген* — сегодня
*кичə* — вчера
*иртəгə* — завтра
*берсекӨнгə* [берсекӨңгə]— послезавтра
*иртəн* — утром
*кӨндез* [kšнäšз] — днем
*кич белəн* — вечером
*тӨнлə* [тӨннə] — ночью
*ике кӨннəн* — через два дня
*Өч елдан* — через три года
*Өч атна (элек)* — три недели (тому назад)
*биш ай* — пять месяцев
*унике кӨн* — двенадцать дней
*дҮрт кӨнгə* [kšžг□]— на четыре дня
*Өч айга* — на три месяца
*Өченче* [өчөнче] *кӨн* — позавчера
*Үткəн атнада* — в прошедшую неделю

Вы, вероятно, помните, что числительные в татарском предложении не изменяются, как в русском: они во всех случаях перед существительными остаются неизменными. Например:

*Өч минут калды.*
*Безгə биш кунак килде.*
*Син миңа ике сум акча бир əле.*
*əни миңа Өч китап алган.*
*Галия бер алма бирде.*

*Сиңа ун сум кирәкме?*
*Апаның дҮрт кызы бар.*

Поговорим по-татарски:

1. — *Син кайчан киләсең?*
   — *Иртәгә.*
   — *БҮген.*
   — *БерсекӨнгә.*
   — *Иртән.*
   — *КӨндез.*
   — *Кич белән.*
2. — *Син кайчан китәсең?*
   — *Өч кӨннән.*
   — *Бер атнадан.*
3. — *Син кайчан кайтасың?*
   — *Иртәгә.*
   — *Ярты елдан.*
   — *Бер айдан.*
4. — *Син кайчан укыйсың?*
   — *БҮген.*
5. — *Син кайчан кайттың?*
   — *БҮген.*
6. — *Син кайчан укыдың?*
   — *Кичә.*
7. — *Марат кайчан килгән?*
   — *Өченче кӨн.*
8. — *Концерт кайчан булган?*
   — *Үткән атнада.*
9. — *Габдулла Тукай кайчан туган?* (родился)
   — *Г.Тукай (бер) мең сигез йӨз сиксән алтынчы елда туган.*
10. — *Син кайчан тугансың?*
    — *Мин (бер) мең тугыз йӨз сиксән алтынчы елда туганмын.*
11. — *Синең әниең кайчан туган?*
    — *әнием (бер) мең тугыз йӨз утыз сигезенче елда туган.*

**Сколько тебе (Вам) лет? — Сиңа (Сезгә) ничә яшь?**

1. — *Сиңа ничә яшь?*
   — *Унике.*
2. — *МӨнирә, сиңа ничә яшь?*
   — *Унсигез. ә сиңа?*

— *Егерме.*

3\. — *Салих, Сезгә ничә яшь?*

— *Кырык. ә Сезгә?*

— *Миңа утыз ике.*

4\. — *Галия ханым, гафу итегез, Сезгә ничә яшь?*

— *Утыз сигез.*

5\. — *Хәниф улым, сиңа ничә яшь?*

— *Егерме биш, бабай.*

6\. — *Бабай, сиңа ничә яшь?*

— *ЙӨз дә ике, кызым.*

— *Ай-ай-ай! Сез бик яшь, бабай!* (*яшь* — молодой).

7\. — *Бу балага ничә яшь?*

— *Бер яшь тә ике ай.*

8\. — *РӨстәм, сиңа бҮген ничә яшь тулды* (исполнилось)?

— *Утыз яшь.*

9\. — *АйгӨл, әниеңә ничә яшь?*

— *Кырык ике.*

— *әтиеңә ничә яшь?*

— *Илле.*

— *ә сиңа ничә яшь?*

— *Унсигез.*

На прощание **татарские пословицы.**

*Биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян* [биш тийеннек къуйан, ун тийеннек зыйан] — Заяц на пять копеек, расхода на него на десять копеек.

*Вакытын югалткан — малын югалткан* [–акъытын йу„алткъан, малын йу„алткан] — Потерявший свое время, потерял и богатство (ср. Время — деньги)

*Егет кеше ике сӨйләми* [йегет кеше ике сӨйләми]. — Молодец не говорит дважды.

*Байлык бер айлык, саулык — гомерлек* [байлыкъ бер айлыкъ, са–лыкъ „ӨмӨрлек] — Богатство на месяц, здоровье — на всю жизнь.

Сау булыгыз! Сезгә уңышлар телим.




# Урок двадцать первый

(Егерме беренче дәрес)

— Исәнмесез, дуслар (друзья)!

Продолжаем изучение слов и выражений, относящихся к теме «Время».

**Времена года.**

Помните эти слова?

*ел* [йыл] — год

*яшь* [йәш] — лет

*ай* — месяц

*атна* — неделя

*ярты ел* — полгода

К ним еще добавим следующие:

*быел* — в этом году

*былтыр* — в прошлом году

*киләсе елга* — на будущий год

*ике елдан* — через два года

*ярты елдан* — через полгода

*ун елдан* — через десять лет

Среди этих слов есть одно слово, возможно, знакомое вам. Это — *«былтыр»* — в прошлом году (в году минувшем).

Вспомнили? Да, это герой поэмы Г.Тукая «Шурале» Былтыр в ответ на вопрос Шурале так назвал свое имя. Когда к обманутому Шурале пришли его соплеменники, на их вопрос, кто же прищемил его палец, шурале ответил:

— Былтыр (в году минувшем).

Тогда все шурале подняли беднягу на смех: дело было в году минувшем, разве из-за прошлогодней боли нынче плачут?

Времена года называются в татарском языке так:

*яз* [йаз] — весна
*Җәй* — лето
*кӨз* — осень
*кыш* [къыш] — зима.

Соответственно ***весной, летом, осенью*** *и* ***зимой*** будет так:

*яз кӨне*
*Җәй кӨне*
*кӨз кӨне*
*кыш кӨне*

Можно сказать эти же понятия одним словом:

*язын*
*Җәен*
*кӨзен*
*кышын*

Чтобы поговорить о временах года, надо знать слова, связанные с ними. Вспомним старые и запомним новые слова:

*чәчәк* — цветок
*яшел* — зеленый
*сары* — желтый
*агач* [а„ач] — дерево
*кар* [къар] — снег
*яңгыр* [йаң„ыр] — дождь
*Җил* — ветер
*озын* [озон] — длинный

*кыска* [къыскъа] — короткий
*кояш* [къойаш] — солнце
*кош* [къош] — птица
*яфрак* [йафракъ] — лист
*Җиләк* — ягода
*Җылы* — тепло
*салкын* [салкъын] — холодно, холодный
*эссе* [ессе] — жарко, жаркий
*ашлык* [ашлыкъ] — хлеба
*урман* — лес
*елга* [йыл„а] — река
*рәхәт* — приятно
*бодай* — пшеница
*кҮк* — небо
*яшенле яңгыр* — гроза
*кырау* [кыра–] — заморозки
*йолдыз* [йолдоз] — звезда
*салават кҮпере* [сала–ат кҮпере] — радуга
*боз* — лед



Поговорим по-татарски:

1. — *Син кайсы вакытны* (время года) *яратасың?*
   — *Җәйне. ә син?*
   — *ә мин — язны.*
2. — *Син кышны яратасыңмы?*

*— әйе.*

3. *— Син язны яратасыңмы?*

*— Юк. Мин Җәйне яратам.*

4. *— Син Җәйне яратасыңмы?*

*— әлбәттә* (конечно).

5. *— Син Җәй кӨне авылга кайтасыңмы?*

*— әйе.*

*— Авылда кемнәр бар?*

*— әби, бабай.*

*— әбиеңә ничә яшь?*

*— Җитмеш.*

*— Бабаеңа ничә яшь?*

*— Җитмеш ике.*

*— Җәй кӨне авылда рәхәтме?*

*— Бик рәхәт.*

6. *— Быел кӨз озын булды.*

*— әйе шул. Бик матур булды.*

*— әйе.*

7. *— Быел кӨз кӨне конференция булды.*

*— Нинди?*

*— Математикадан.*

*— Син бардыңмы?*

*— Юк. Мин командировкага бардым.*

8. *— Җәй кӨне кайда ял итәсез* (отдыхаете)?

*— Дачада.*

*— Дачагыз еракмы?*

*— Ерак тҮгел. Поезд белән барабыз.*

*— Елга бармы?*

*— Бар.*

*— Нинди елга?*

*— Идел.*

*— И-и-их, яхшы икән!*

9. *— Былтыр кыш Җылы булды.*

*— әйе шул. Кар да кҮп тҮгел иде.*

*— әйе.*

10. *— Син ялны* (отдых, отпуск) *кайчан аласың?*

*— Җәй кӨне.*

*— ә мин — кӨз кӨне. КӨз кӨне дачада бик рәхәт.*

11. — *БҮген шундый* (такой) *матур кӨн!*

— *әйе шул. Җил дә юк. Җылы.*

— *әйдә, дачага барабыз!*

— *әйдә!*

12. — *Җиләк бармы урманда?*

— *Бар.*

— *КҮпме?*

— *Бик кҮп.*

— *Иртәгә барабызмы?*

— *әйдә.*

13. — *Яфраклар яшелме?*

— *Юк, сары.*

14. — *Агачлар яшелме?*

— *әйе, ямь-яшел.*

15. — *Агачлар сарымы?*

— *әйе, сап-сары.*

16. — *әйдә, урманга барабыз.*

— *Кайчан?*

— *Иртәгә. Урманда гӨмбә кҮп.*

— *Ярар.*

17. — *Иртәгә салкын буламы?*

— *әйе. Радиодан әйттеләр.*

— *Ничә градус?*

— *Егерме градус.*

18. — *Иртәгә яңгыр буламы?*

— *Юк. Иртәгә Җылы, кояш.*

— *Ничә градус?*

— *Егерме Җиде.*

19. — *Сезнең урманда Җиләк кҮпме?*

— *КҮп.*

— *Нинди Җиләкләр бар?*

— *Җир Җиләге, каен Җиләге, кызыл бӨрлегән, кара бӨрлегән бар.*

20. — *Кыш кӨне рәхәтме?*

— *Рәхәт.*

21. — *Син чаңгы шуасыңмы?* (ты катаешься на лыжах?)

— *әйе. Минем чаңгым бар.*

— *әйдә, иртәгә урманга барабыз.*

*— Вакытым юк шул. Татар телен Өйрәнәм.*
22. *— Кичә салкын булдымы?*
*— әйе. Бик салкын.*
*— Җил булдымы?*
*— Булды.*
*— Туңдыңмы?* (замерз?)
*— әйе, туңдым.*
*— Кайчан кайттыгыз?*
*— Сәгать сигездә.*
23. *— Быел Җәй кӨне син комбайнда эшләдеңме?*
*— әйе.*
*— Нинди комбайнда?*
*— «Дон»да.*
*— Ашлык уңганмы?* (уродился ли хлеб?)
*— әйе. Бер гектардан 30 центнер булды.*
*— Яхшы булган. КҮпме бодай бирделәр?*
*— 40 центнер бирделәр.*
*— Шәп!* (Отлично!)
24. *— Кошлар очып киттеләрме?* (птицы улетели?)
*— әйе.*
25. *— Кошлар очып килделәрме?* (прилетели?)
*— Юк әле.*
*— Кайчан килерләр икән?*
*— Бер-ике атнадан.*
26. *— Кояш кыздырамы?* (печет ли солнце?)
*— әйе.*
*— Бик эссе, әйеме?*
*— әйе. әйдә, су эчәбез.*
*— әйдә, кайда су бар?*
*— әнә киоскыда.*
*— Бер шешә* (бутылка) *10 сум.*
*— Ай-ай кыйбат!*
*— Алабызмы?*
*— Алабыз.*
27. *— Казанкада су Җылымы?*
*— Җылы.*
*— Су коенырга* (купаться) *барабызмы?*
*— әйдә. Тагын кем бара?*

*— Рәис, Рушан.*

*— әйдәгез тизрәк.*

*— әйдә, киттек.*

*28. — КӨз кӨне урман бик матур, әйеме?*

*— әйе, яфраклар сары, кызыл. КҮк зәңгәр. Кояш балкый* (сияет).

*29. — БҮген яңгыр булачак.*

*— Шулаймыни?! Кем әйтте?*

*— Радиодан әйттеләр.*

*— Кичә бездә боз яуды.*

*— Кайчан?*

*— ТӨнлә.*

*30. — БҮген тӨнлә яшенле яңгыр булды.*

*— Мин ишетмәдем* (не слышала).

*— Иртәгә кӨн кояшлы була.*

*— Урманга барабыз, әйеме?*

*— әйе.*

*31. — БерсекӨнгә салкыннар башлана* (начинаются).

*— Ничә градус?*

*— 30 градус булачак.*

*— Кичә авылга кайткан идек. Буран булды. Кар яуды.*

*— ә бездә булмады.*

*32. — Кызым, Җил исә, тәрәзәләрне яп әле* (закрой-ка окна).

*— Ярар, әни.*

*33. — Нинди матур кҮк! Йолдызлар кҮп!*

*— әйе. әнә йолдыз атылды!*

*— Мин дә кҮрдем.*

*34. — Яңгырдан соң салават кҮпере чыккан. Кара әле!*

*— әйе, кҮрәм. Нинди матур!*

*35. — Иртәгә кырау булачак!*

*— Алайса* (тогда) *бҮген бакчага барырга кирәк.*

*— Ник?*

*— Помидорларны капларга* (закрыть) *кирәк.*

*— әйе шул.*

*36. — Улым, тор инде, тор!*

*— Кояш чыкмаган әле, әни.*

*— Хәзер чыга ул.*

*37. — БҮген кояш кичке сәгать 8 дә бата (байый)* (заходит).

*— Каян беләсең?*

*— Календарьга язганнар.*

*38. — ДҮшәмбе кӨнне яңгыр яуды.*

*— Син кҮрдеңме?*

*— әйе.*

*39. — И-и-и, шундый кӨчле яшен булды!*

*— □айчан?*

*— Сишәмбе кӨнне.*

*40. — Шимбә кӨнне боз яуган.*

*— Кайда?*

*— Арча районында.*

*41. — Җомга кӨнне кӨн аяз* (ясно) *була.*

*— Җиләккә барабызмы?*

*— Аяз булса* (если будет ясно) *барабыз.*

*42. — Якшәмбедә буран булды. Шундый салкын иде. КӨчле Җил исте.*

*— Бездә булмады.*

**Задание 1.** Попробуйте понять напечатанную в газете сводку погоды.

**Һава торышы**

*Синоптиклар хәбәр иткәнчә, бҮген, 28 июнь кӨнне, алмашынучан болытлы Һава, явымсыз диярлек. Температура тӨнлә 9-11, кӨндез 21-23 градус Җылы. Һава басымы тӨшә, дымлылык арта.*

Многое вы поняли, но есть несколько незнакомых слов:

*хәбәр иткәнчә* — как сообщают; *алмашынучан болытлы Һава* — облачно с прояснениями; *явымсыз* — без осадков; *диярлек* — почти; *Һава басымы* — давление; *тӨшә* — понижается; *дымлылык* — влажность; *арта* — повышается.

**Задание 2.** Продолжите предложения.

Кышын кӨннәр ......

Язын кӨннәр .......

Җәен кӨннәр .......

КӨзен кӨннәр .......

Быел мин дачада ......

Былтыр без авылда ........

Киләсе елга алар Ялтада .......
Яңгырдан соң .......
КҮктә кояш .......
Якшәмбедә Иделдә ........
Кичә тӨнлә кар .......

**Задание 3.** Запомните пословицы:

*Ай кҮрде — кояш алды* [ай кҮрде — къойаш алды] — букв. Месяц увидел — солнце забрало. (Т.е. осень быстро, в мгновение ока).

*Былтыр кысканга быел кычкырмыйлар* [былтыр къыскъаң„а быйыл къычкъырмыйлар]. — Из-за того, что прищемили в прошлом году, нынче не жалуются.

*Каз килсә — яз килә* [къаз килсә — йаз килә]. — Если прилетел гусь — пришла весна.

*Язгы кӨн ел туйдыра* [йаз„ы кӨн йыл туйдыра] — Весенний день год кормит.

*Алма пеш, авызыма тӨш* — Созрей, яблоко, упади в мой рот.

Сау булыгыз! Уңышлар сезгә!




# Урок двадцать второй

(Егерме икенче дәрес)

Исәнмесез!
Хәерле кӨн!
Продолжаем изучение глагольных времен.

**Незавершенное прошедшее время.**

Это время обозначает действие, которое не завершилось в прошлом и связано с другим действием. Оно образуется при помощи присоединения к корню или основе глагола аффиксов **-а иде/-ә иде, -ый иде/-и иде** (иде — вспомогательный глагол «быть»).

**Единственное число.**

| | | |
|---|---|---|
| *Мин бар-а иде-м* | *әйт-ә иде-м* | (ходил, говорил) |
| *Син бар-а иде-ң* | *әйт-ә иде-ң* | (ходил, говорил) |
| *Ул бар-а иде—* | *әйт-ә иде-—* | (ходил, говорил) |

**Множественное число**

| | | |
|---|---|---|
| *Без бар-а иде-к* | *әйт-ә иде-к* | (ходили, говорили) |
| *Сез бар-а иде-гез* | *әйт-ә иде-гез* | (ходили, говорили) |

*Алар бар-а-лар иде-* *әйт-ә-ләр иде* (ходили, говорили)

Посмотрим, как это время употребляется в речи:

1. *Мин кинога бара идем, ГӨлфияне кҮрдем.* (Я шел в кино, увидел Гульфию).

2. *Син әйтә идең: «Казанга кил».* (Ты говорил: «Приезжай в Казань»)

3. *әни әйтә иде: «Укы, балам!»* (Мама говорила: «Учись, дитя мое!»)

4. *Ул яза иде: анда Җиләк кҮп икән.* (Он писал: там, оказывается, много ягод).

5. *Сәрия белә иде.* (Сария знала).

6. *Хәлим мине белә иде.* (Халим знал меня).

7. *Суфия Җырлый иде.* (Суфия пела).

8. *Кояш балкый иде.* (Сияло солнце).

9. *Яңгыр ява иде.* (Шел дождь).

10. *Җил исә иде.* (Дул ветер).

11. *Паркта агачлар Үсә иде.* (В парке росли деревья).

12. *Кар ява иде.* (Шел снег).

13. *Концертларда Марат әхмәтов скрипкада уйный иде.* (На концертах Марат Ахметов играл на скрипке).

Теперь попробуем поговорить по-татарски:

1. — *Нурия, син Коляны белә идеңме?*
— *әйе, белә идем. Коля нишләгән?* (что сделал?)
— *Диссертация яклаган* (защитил).
— *Молодец!*

2. — *Мансур, сезгә бер әби керә иде. Кайда ул хәзер?*
— *Ул авылда.*
— *Аның исеме ничек?*
— *Мәрхәбә әби.*
— *Аңа ничә яшь?*
— *Сиксән бер.*
— *Ул тагын* (еще) *киләме?*
— *әйе, кыш кӨне ул әби Казанга килә.*

3. — *Наилә, мин кибеткә бара идем, ГӨлфияне кҮрдем.*
— *Кайчан?*
— *БҮген.*

*— ГӨлфия Казанга килгәнмени?*

*— әйе шул. Ул Тукай урамында яши. Сиңа кҮп сәлам әйтте.*

*— Рәхмәт.*

4\. *— Мин чәй эчә идем, Равия керде.*

*— Нинди Равия?*

*— Белмисеңмени? Ул кибеттә эшли.*

*— ә-ә-ә! Беләм.*

*— Аның әнисе МаҺинур апа да кибетче* (продавщица).

**Задание 1.** Я напишу слова в столбик, пропущу отдельные буквы, вы их дополните и переведите. Затем с этими словами составьте предложения и мини-диалоги.

*р.хмәт*
*ис.нмесез*
*а.ый*
*б.ла*
*б.бай*
*у.ырыгыз*
*с.лге*
*нәрс.?*
*н.чек?*
*к.пме?*
*н.нди?*
*кир.к*
*к.йчан?*
*к.йда?*
*т.гыз*
*китап.ар*
*мәч.т*
*м.тур*
*х.тын*
*б.ш*
*к.л*
*ч.ч*
*б.рын*
*к.з*
*.стәл*
*з.р*
*а.ыл*
*ва.ыт*
*.азан*
*.иләк*
*к.чкенә*
*ч.лбар*
*шә.әр*
*Мәскә.*
*чист.*
*к.тап*
*д.рт*
*а.ты*
*с.гез*
*к.чә*
*ук.чы*
*а.бур*
*д.рес*
*б.шле*
*д.ртле*
*т.нәфес*
*укы.учы*
*б.рәңге*
*к.бестә*
*су.ан*

| | |
|---|---|
| *б.ген* | *к.шер* |
| *ирт.гә* | *м.й* |
| *ту.ма* | *к.ймак* |
| *икм.к* | *эр.мчек* |
| *ак.а* | *к.бет* |
| *.шел* | *т.н* |
| *з.ңгәр* | *к.н* |
| *к.зыл* | *с.гать* |
| *с.ры* | *б.ген* |
| *ч.гендер* | |

**Задание 2.** Слова из первого задания поделите на твердые и мягкие и напишите в два столбика.

**Задание 3.** Выразите свое отношение к первой реплике.

1. — Иртәгә яңгыр була.

— ----------------------------.

2. — Бүген көчле җил.

— -------------------------.

3. — Кичә салкын булды.

— ----------------------------.

4. — Берсекөнгә +15° булачак.

— -----------------------------------.

**Задание 4.** Поставьте глагольные сказуемые в незавершенном прошедшем времени (-а иде).

1. Мин ул вакытта Казанда ...
2. Син анда ...
3. Ул безгә кич белән ...
4. Без урманга җиләккә ...
5. Сез аларга кунакка ...
6. Алар университетта ...

Сау булыгыз!

Сезгә уңышлар юлдаш булсын! (*Букв.* Пусть успехи будут вам спутником!)




# Урок двадцать третий

(Егерме Өченче дәрес)

Исәнмесез!

Хәерле кӨн!

В татарском языке, как, пожалуй, и в любом другом, существует определенный набор стереотипов общения. Они занимают довольно большую часть диалогов. Мы сделаем на этом уроке так: дадим диалоги без перевода и транскрипции. Учитывая ваши знания, полученные на предыдущих уроках, мы решили дать вам возможность позаниматься с текстами самостоятельно, без «подсказки». При необходимости обратитесь к татарско-русскому словарю.

**1. Минем исемем...**

— *Исәнмесез! Минем исемем — Кәрим, Кәрим Фәйзуллин.*

— *Хәерле кӨн! ә минем исемем — әхәт Сафиевич. Рәхим итегез. Сез каян килдегез?*

— *Петербургтан.*

— *Без әле очрашырбыз бит?*

— *әлбәттә. Хәзергә сау булыгыз.*

**2. Сез танышлармы?**

— *Сез танышлармы?*

— *Юк әле.*

— *Таныш булыгыз: МӨдәрис, Суфия.*

*— Рәхмәт. Без бик шат.*

*— МӨдәрис безгә Ригадан килгән. Ул Казан карарга килгән.*

**3. Исемегез ничек?**

*— Кем сӨйли?*

*— Алло! Мин сезне начар ишетәм... Исемегез, фамилиягез ничек? Алло? Кем сӨйли? Ишетелми (не слышно). Тагын шалтыратыгыз әле (позвоните, пожалуйста).*

**4. Нихәл?**

*— Сәлам, Рәшит!*

*— Сәлам. Сине кҮптән кҮргән юк. Нихәл?*

*— әйбәт. ә синең хәлләр ничек?*

*— Ярыйсы. Син кайсы якка?*

*— Уңга. ә сиңа?*

*— Сулга. Ярый, сау бул.*

**5. Без сезне кунакка чакырабыз.**

*— Безгә кермисезме?*

*— Бик рәхәтләнеп. Кайчан?*

*— Иртәгә. Хатыныгыз белән килегез.*

*— Ярый. Сәгать ничәдә?*

*— Алтыда.*

*— Рәхмәт. Без килербез.*

**6. Сезне кҮрҮемә мин бик шат!**

*— Исәнмесез! Сезне кҮрҮемә мин бик шат.*

*— Исәнмесез! Кайчан килдегез?*

*— Кичә.*

*— ә кайсы бҮлмәдә яшисез?*

*— Ике йӨз унынчы бҮлмәдә.*

*— ә мин дҮрт йӨз егерме беренчедә. Кунакка керегез.*

*— Рәхмәт.*

**7. Ялгышмасам...**

*— Ялгышмасам, сез Сания Хәкимовна буласыз бит?*

*— Юк, сез ялгышасыз.*

*— Гафу итегез, зинҺар.*

*— Булгалый (бывает).*

**8. Сез номерны ялгыш (ошибочно) Җыйгансыз.**

*— Алло, Мансурны телефонга чакырыгыз әле.*

*— Сез номерны ялгыш Җыйгансыз.*

*— Гафу итегез, сезнең номерыгыз 76-32-41-ме?*

*— Юк.*

**9. Син кирәк идең.**

*— Сәлам, Рушат! Сине эзли идем.*

*— Сәлам, минеме?*

*— әйе, сине. Бик кирәк идең.*

*— Ни әйтәсең бар?*

*— Ашыкмыйсыңмы? әйдә, утырыйк әле.*

*— әйдә.*

**10. Оныта язганмын...**

*— Оныта язганмын, син Ринатны беләсең бит?*

*— Беләм.*

*— Шул Ринат сиңа сәлам әйтергә кушты.*

*— Ничек? Ул Казандамыни?*

*— әйе. Ул телефоннан әйтте. Син аңа шалтырат, яме. Аның телефоны — 53-04-67.*

*— Ярый, рәхмәт, шалтыратырмын.*

**11. Син кайда йӨрдең?**

*— Алло!*

*— әйе, тыңлыйм.*

*— Алло! Син кайда йӨрисең? КӨне буе сиңа шалтыратам!*

*— Кичә Өйдә булмадым шул. Дачага барган идем. Йомышың бармыни?*

*— Йомыш юк, бҮгенге концертка билетлар алган идем. Барабызмы?*

*— Барабыз. Рәхмәт.*

**12. Бер сорау бар. МӨмкинме?**

*— Бер сорау бар. МӨмкинме?*

*— әлбәттә. Аңлашылмадымы? Сорагыз.*

*— Менә монда бер сҮз аңлашылмый...*

**13. Сез нәрсә дидегез?**

*— Гафу итегез, сез нәрсә әйттегез?*

*— Сез минем белән килешмисезмени?*

*— Юк-юк, мин сез әйткәнне язып куймакчы идем.*

*— Шулаймыни? Алайса кабатлыйм.*

**14. Шулаймыни? Аңа ни булган?**

*— Галия әсхәтовна!*

*— Тыңлыйм.*

*— Марат Сафин бҮген дәрескә килә алмый.*

*— Шулаймыни? Аңа ни булган?*

*— Ул авырый.*

*— әйтҮегезгә рәхмәт, тизрәк терелсен.*

**15. Ничәле алдың? Котлыйм!**

*— Ничек, имтихан бирдеңме? Ничәле алдың?*

*— Бишле.*

*— Котлыйм! ә син курыккан идең.*

**16. Минем сезгә бер Үтенечем бар.**

*— Минем сезгә бер Үтенечем бар.*

*— Рәхим итегез, нинди?*

*— Класска кереп, Мансур Гариповны чакырыгыз әле.*

*— Кайчан килсен?*

*— Хәзер Үк.*

*— Рәхмәт сезгә.*

**17. Барыгыз да Җыелдыгызмы?**

*— Барыгыз да Җыелдыгызмы?*

*— Юк әле, Өч кеше юк.*

*— Кемнәр юк?*

*— Рифат,Зилә, Шакир юк.*

*— Нишләп юк икән?*

*— Хәзер килеп Җитәрләр.*

**18. Юк, ярамый. РӨхсәт ителми.**

*— Энем, Сезнең папкагызда нинди китап ул?*

*— СҮзлек. әллә ярамыймы?*

*— Ярамый. Уку залына Үзең белән китап алып керергә ярамый.*

*— Миңа бик кирәк иде.*

*— Тагын бер кат әйтәм, ярамый.*

*— Мин нишлим соң?*

*— Уку залына шул сҮзлекне фондтан яздырып алыгыз. алдагы фондтан сорарга мөмкин.*

**19. СҮзекләр кайда икән?**

*— Рабига апа, сҮзлекләр кайда икән?*

*— Сезгә кайсысы кирәк?*

*— Миңа «Татар теленең аңлатмалы сҮзлеге» кирәк.*

*— Ничәнче томы?*

*— Икенче.*

*— «СҮзлеклəр» исемле стеллажларда Өстəн икенче рəттəн карагыз.*

*— Рəхмəт Сезгə!*

**20. Хəзер вакытым юк. КӨтеп торыгыз.**

*— Мансур əхмəтович, Сезгə мӨмкинме?*

*— Хəзер вакытым юк. КӨтеп торыгыз. Миңа бер документ язып бетерергə кирəк иде.*

*— КҮпме кӨтим?*

*— 15 минут.*

*— Ярый, рəхмəт. КӨтеп торырмын.*

**21. Уйлап карарга кирəк.**

*— Сəлим əфəнде, иртəгə Җыелышта чыгыш ясыйсызмы?*

*— Уйлап карарга кирəк. Җыелыш ничəдə була?*

*— Кичке биштə.*

*— Рəхмəт.*

**22. əйдəгез, болай сӨйлəшəбез...**

*— РӨстəм, сез бҮген əзерме?*

*— Юк, шул.*

*— Алайса, əйдəгез, болай сӨйлəшəбез: икенче атнага эшегезне бӨтенлəй тəмамлап бетерегез. Шуннан соң сӨйлəшербез.*

**23. Сезне сорыйлар.**

*— Равил əфəнде, Сезне сорыйлар.*

*— Кем?*

*— Бер иптəш.*

*— Ул кайдан?*

*— Уфадан.*

*— əйтегез, керсен. Мин аны кӨтəм.*

**24. Сезгə комачауламадыммы?**

*— Ярыймы?*

*— Керегез.*

*— Мин сезгə комачауламадыммы?*

*— Юк-юк. Рəхим итегез.*

*— Миңа бер хат килде. Ул — испан телендə, тəрҖемə итəргə кирəк иде.*

*— əйдəгез, карап карыйк.*

**25. Мин сезгə комачауламыйммы?**

*— Мин сезгə комачауламыйммы?*

*— Һич юк. Оялмагыз, әйтегез. Сез миңа Һич тә комачауламыйсыз.*

*— Рәхмәт...*

**26. Сез белмисезме, Шамил кайда икән?**

*— Сез белмисезме, Шамил кайда икән?*

*— Ул кҮрше бҮлмәдә.*

*— Мин аннан карадым, ул чыккан.*

*— Алайса, белмим шул.*

**27. Сезнең вакытыгыз булырмы икән?**

*— Исәнмесез!*

*— Рәхим ит, Рәйсә! Ни йомыш?*

*— Сезнең вакытыгыз булырмы икән, Котдус ага. Бер соравым бар иде.*

*— Тыңлыйм, Рәйсә.*

**28. Тулай торакта.**

*— Ярыймы, Ләйсән?*

*— Керегез. Мин менә шунда яшим.*

*— БҮлмәгез бик матур. Якты. Чиста. Бу сезнең китаплармы?*

*— әйе. □арагыз. Мин чәй куям.*

*— Рәхмәт.*

**29. Мин аңа охшаганмы?**

*— Бу — минем әнием. Мин аңа охшаганмы?*

*— әйе, бик тә. Бигрәк тә кҮзең, чәчең. ә бу кем?*

*— Бу — минем абыем. Ул әтиемә охшаган.*

**30. Мин дә сезнең белән!**

*— Сез кая? Киногамы?*

*— әйе.*

*— Мин дә сезнең белән. Ярыймы?*

*— әлбәттә. әйдә, киттек.*

**31. Белмим, кем булды икән?**

*— Ришат, сине бер абый сорады.*

*— Кайчан?*

*— Бер сәгать элек.*

*— Нинди абый?*

*— Картрак кына. Плащ кигән. Озын буйлы.*

*— Ул бер сҮз дә әйтмәдеме?*

*— Юк.*

*— Белмим, кем булды икән?*

**32. Тәбриклим. Сәламәтлек, уңышлар, бәхет телим.**

*— ЗӨҺрә, кара әле. Морат бәйрәмгә телеграмма Җибәргән.*

*— Кая, укыйк әле: «Бәйрәм белән тәбриклим. Ныклы сәламәтлек, зур уңышлар Һәм ак бәхетләр телим».*

**33. Хәзер әйтҮдән файда юк.**

*— Җәмилә, Үпкәләмә инде. Мин чыннан да уйламаганмын.*

*— Хәзер әйтҮдән ни файда. Теге вакытта мин сине кисәттем бит.*

*— Бик кҮңелсез булды инде бу. Гафу ит мине.*

**34. Безгә китәргә вакыт. Рәхмәт Сезгә.**

*— Камилә апа, безгә китәргә вакыт.*

*— Шулаймыни? Бераз утырыгыз әле.*

*— Вакытыбыз юк шул, Камилә апа. Баланы йоклатасы бар.*

*— Китәсезмени?*

*— әйе. Зур рәхмәт Сезгә.*

**35. Егыла кҮрмә! Монда тайгак!**

*— әле тагын кҮпме барасы бар? Мин арыдым.*

*— Бераз тҮз инде. КҮп калмады.*

*— Ай, егыла яздым.*

*— Егыла кҮрмә! Монда тайгак. Миңа тотын.*

**36. Һич булмый.**

*— Ял кӨнне ни эшләргә Җыенасыз?*

*— Театрга барабыз.*

*— Бәлки, безгә кунакка килерсез?*

*— Юк, рәхмәт. Булмый. Без бӨтен гаиләбез белән театрга барабыз.*

**37. Берни тҮгел.**

*— Булат, син кибеткә барасыңмы?*

*— әйе. Сиңа берәр нәрсә кирәкме?*

*— Миңа ярты икмәк ал әле.*

*— БҮтән әйбер кирәк тҮгелме?*

*— Юк. Рәхмәт сиңа.*

*— Берни тҮгел.*

**38. Яңа хәбәр ишеттеңме?**

*— Яңа хәбәр ишеттеңме? Безнең институтка фин татарлары килгән.*

*— Кит аннан?! Кемнәр?*

*— Ике ир кеше, бер ханым.*

*— Кайчан килгәннәр?*

*— Кичә.*

*— Ничә кӨнгә?*

*— Бер атнага.*

**39. Кемнең зонтигы калган?**

*— Иптәшләр, кемнең зонтигы калган?*

*— Бу ЗӨҺрәнең зонтигы бит. Миңа бирегез, мин аңа тапшырырмын.*

*— Ярар. Мә!*

**40. Кайда очрашабыз?**

*— Кайда очрашабыз?*

*— әбҖәлилов тукталышында.*

*— Син киләсеңме?*

*— Белмим шул. Ләкин син мине кӨт.*

*— Ярар. КӨтәрмен.*

*— Ярый, ул вакытка мин килермен.*

*— СӨйләштек.*

*— әйе. Хәзергә сау бул!*

**41. Бер минут кӨтеп тор, мин — хәзер!**

*— Бер минут кӨтеп тор, мин — хәзер!*

*— Син кая?*

*— Хәзер киләм. Киоскыдан газета алам.*

*— Миндә бар бит.*

*— Нинди газета?*

*— «Татарстан яшьләре».*

*— Миңа «Ватаным Татарстан» кирәк шул.*

*— Ярый. Мин кӨтәм.*

**42. Борчылма, ничек тә Өлгерербез.**

*— Ай, соңга калабыз бит.*

*— Борчылма, ничек тә Өлгерербез. Хәзер берәр такси туктатырбыз.*

*— Юк бит такси.*

*— Борчылма, килер әле.*

**43. Аның Өчен мин бик шатмын.**

*— Син Айдар Кәримовны беләсеңме?*

*— Ул Тел, әдәбият Һәм сәнгать институтында эшлиме?*

*— әйе. Ул диссертация яклаган.*

*— Шулаймыни?! Мин аның Өчен бик шат. Ул бик сәләтле яшь галим.*

**44. Хәлегез ничек?**

*— Хәлегез ничек?*

*— Бик әйбәт тҮгел. Мин бераз авырыйм.*

*— Врач кирәкме?*

*— Хәзергә кирәк тҮгел.*

**45. Өйгә табиб чакырырга мӨмкинме?**

*— Өйгә врач чакырырга мӨмкинме?*

*— МӨмкин. Сезнең фамилиягез ничек?*

*— Сабирова.*

*— Исемегез?*

*— Камилә.*

*— әтиегезнең исеме?*

*— Дамир.*

*— Кай тӨшегез авырта?*

*— Кан басымы кҮтәрелде.*

*— Адресыгыз нинди?*

*— Татарстан урамы, 8, 20-нче фатир.*

*— Булды. Табиб сезгә тӨштән соң сәгать 3тә килер.*

*— Рәхмәт сезгә.*

**46. Миңа табибка кҮренергә кирәк иде.**

*— Участок табибы кирәкме сезгә?*

*— әйе. Миңа бассейнга йӨрергә белешмә кирәк.*

*— Сезне табиб хәзер кабул итәр. Аның исеме — Суфия ханым, фамилиясе — Ризванова.*

**47. Сез кайсы кабинетка?**

*— Сез кайсы кабинетка?*

*— 21-нчегә. Сездән соң кеше бармы?*

*— Юк.*

*— Мин сездән соң булам.*

*— Ярый.*

**48. Бу дарулар бармы сездә?**

*— Бу дарулар бармы сездә?*

*— Рецептыгыз бармы?*

*— Бар. Рәхим итегез.*

*— Менә бусы юк. Ә бусы бар. Кассага 26 сум 95 тиен тҮләгез.*

*— Кайсы бҮлеккә?*

*— Икенче бҮлеккә.*

**49. Соң шалтыратканга гафу итегез.**

*— Мәрьям апа, соң шалтыратканга гафу итегез. Иртәгә сезнең вакытыгыз бармы?*

*— Бар.*

*— Сез эшкә кайчан киләсез?*

*— Иртәнге унда.*

*— Мин унберенче яртыга киләм. Сезнең эшегезне шунда алып килермен.*

*— Рәхмәт Сезгә. Тыныч йокы!*

**50. әйбәт ял итегез!**

*— ТаҺир абый, Сез ялга китәсез икән.*

*— әйе шул, РӨстәм. Иртәгә китәбез.*

*— әйбәт ял итегез, ТаҺир абый.*

*— Рәхмәт, РӨстәм.*

**51. Алло! Белешмәләр бҮлегеме?**

*— Алло! Белешмәләр бҮлегеме?*

*— әйе, тыңлыйм.*

*— әйтегез әле, «Татарстан» поезды кайчан китә икән?*

*— 19 сәгать 8 минутта.*

*— МәскәҮгә кайчан килеп Җитә?*

*— Иртәнге 7дә.*

На этом завершаем наш урок.

Сау булыгыз!

Уңышлар телим!




# Урок двадцать четвертый

(Егерме дҮртенче дәрес)

— Исәнмесез! Хәерле кӨн!

Сегодня мы будем говорить о книгах, библиотеках, печати.

**Книга. Печать.**

Для этого нам нужно познакомиться со словами, относящимися к данной теме.

*Китап* — книга
*язучы* — писатель
*шагыйрь* [ша„ир] — поэт
*шигырь* — стихотворение
*хикәя* — рассказ
*газет* /в разговорный речи гәзит, гәҖит/ — газета
*мӨхәррир* — редактор
*сәркатип* — секретарь
*хәбәрче* — корреспондент
*китапханә* — библиотека
*кызыклы* — интересный
*тыш* — обложка

*калын* — толстый
*нечкә* — тонкий
*рәссам* — художник
*бит* — страница
*бизәлеш* — оформление
*эчтәлек* — содержание
*бҮлек* — глава
*кисәк* — часть
*мәкалә* — статья
*әсәр* — произведение
*нәсер* —стихотворение в прозе
*әкият* — сказка
*тәрҖемә* — перевод
*тәрҖемәче* — переводчик
*мәкаль* — пословица
*бәя* — цена

А теперь познакомимся с глагольной конструкцией **-ган** + аффиксы принадлежности + **бар, юк.** Эта конструкция выражает процесс, когда-то имевший место в жизни кого-то.

| | |
|---|---|
| Минем бар-ган-ым бар (юк). | Я когда-то ходил. |
| Синең бар-ган-ың бар (юк). | Ты когда-то ходил. |
| Аның бар-ган-ы бар (юк). | Он когда-то ходил. |
| Безнең бар-ган-ыбыз бар (юк). | Мы когда-то ходили. |
| Сезнең бар-ган-ыгыз бар (юк). | Вы когда-то ходили. |
| Аларның бар-ган-нары бар (юк). | Они когда-то ходили. |

*1. — Нурия, синең бу китапны укыганың бармы?*
*— әйе, укыганым бар.*
*— ә синең, Нәфисә, укыганың бармы?*
*— Юк, укыганым юк.*
*2. — Синең бу китапны кҮргәнең бармы?*
*— әйе, кҮргәнем бар.*
*— ә синең, Марат, кҮргәнең бармы?*
*— Юк, кҮргәнем юк.*
*3. — Сезнең бу язучыны кҮргәнегез бармы?*

— *әйе, кҮргәнем бар.*

— *ә сезнең, кызлар?*

— *Юк, безнең кҮргәнебез юк.*

**Задание 1.** Проспрягайте глаголы в форме *сӨйләгәнәм бар (юк)* по лицам и числам:

сӨйлә-, аңла-, пеˇер-, бар-, кара-, яз-, әйт-, бие-, Җырла-, кҮр-.

**Задание 2.** Переведите.

Минем бу язучыны кҮргәнем юк.

Синең теге китапны укыганың бар.

Аның бу киноны караганы юк.

Безнең паркка барганыбыз бар.

Сезнең бу чәйне эчкәнегез юк.

Аларның бу музейга барганнары юк.

Теперь можно и поговорить.

*1. — Бу китап кемнеке?*

— *Минеке.*

— *Кайдан алдың?*

— *Китап кибетеннән.*

— *Бәясе ничә сум?*

— *Егерме биш сум.*

— *Тагын бармы?*

— *Бар. Бик кҮп.*

— *Мин дә кибеткә барам әле.*

*2. — Нинди матур китап!*

— *әйе. Бу китап — бҮләк.*

— *Кем бирде?*

— *Дустым Сәрия.*

— *Бик матур бҮләк.*

*3. — Бу китап зур!*

— *әйе. Зур.*

— *Калын да!*

— *әйе.*

— *Рәссамы кем?*

— *Тавил ХаҖиәхмәтов.*

— *Бик матур китап!*

*4. — Бу китапны кем язган?*

*— МӨхәммәт МәҺдиев язган.*

*— Кызыкмы?*

*— әйе. Бик кызык.*

*— Бу — романмы?*

*— әйе.*

*— Исеме ничек?*

*— «Фронтовиклар».*

*— Син укыдыңмы?*

*— әйе, укыдым.*

5. *— Бу шигырьләрне кем язган?*

*— Габдулла Тукай язган.*

*— әйе, Тукайны белмәгән кеше юк.*

*— Син Тукайны укыдыңмы?*

*— Русчасын укыдым.*

*— Тукай шигырьләр, поэмалар, мәкаләләр, проза әсәрләре язган. «ШҮрәле»не беләсеңме?*

*— әйе.*

*— «Китмибез» шигырен беләсеңме?*

*— әйе, беләм.*

*— Тукай балаларга әкиятләр дә язган. «Су анасы»н беләсеңме?*

*— Русча ул «Водяная» дип атала, әйеме?*

*— әйе, дӨрес. Мин сиңа бер шигырь укыйм:*

*әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;*

*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*

*— Бу сҮзләр кайсы әсәрдән?*

*— «Пар ат» шигыреннән. Русча — «Пара гнедых». Аңладыңмы?* (Понял?)

*— Мин «әйтә, намаз, бик матур, Казан» сҮзләрен аңладым.*

*— Мин сиңа Һәр* (каждый) *сҮзне тәрҖемә итәм* (переведу):

*Произносит к утреннему намазу очень красивую, задушевную молитву;*

*О Казань! Страстная Казань! Песенная Казань! Светозарная Казань!*

*— Болай матур тҮгел. Тукай матуррак язган.*

Дорогие друзья! Найдите русский перевод стихотворения «Пар ат» и прочитайте его.

6. — *Теге китапны кҮрсәтегез әле* (покажите-ка).

— *Рәхим итегез* (пожалуйста).

— *Рәхмәт.*

*7. — Бу китап ничә сум?*

*— Кырык Өч сум. Кассага тҮләгез.*

*— Хәзер.*

*8. — Китапта ничә бит бар?*

*— ДҮрт йӨз кырык ике.*

*— Китапта титул бите бармы?*

*— әйе, бар.*

*9. — Бу шигырьне Сәгыйть Рәмиев язган. Беләсеңме?*

*— Юк.*

*— Укыйммы?*

*— Укы.*

*— Тыңла:*

*Мине утка аткан да — син,*
*Мине суга салган да — син,*
*Утта янсам, суга батсам,*
*Тартып алган Аллам да — син!*

*Аңладыңмы?*

*— Кайбер сҮзләрне аңладым:*

*мине* — меня, *син* — ты, *суга* — в воду, *Аллам* — Аллах мой.

*— Мин сиңа тәрҖемә итәм:*

Бросившая меня в огонь — ты,
Бросившая меня в воду — ты,
Если я горю в огне, тону в воде,
Мой Аллах, вытянувший меня — тоже ты!

*Матурмы?*

*— Бик матур. Шигырьнең исеме ничек?*

*— «Син».*

*— Рәхмәт сиңа, Нурия.*

*10. — Казанда китапханәләр кҮпме?*

*— Бик кҮп.*

*— Иң зурлары нинди?*

*— Университет китапханәсе. Анда 5 миллион китап бар.*

*— Тагын?*

*— Татарстан Милли китапханәсе.*

*— Ул кайда урнашкан?*

*— Кремль урамында. Ул университетка бик якын.*

*11. — Миңа бу китапны бирегез әле.*

*— Сез аны 10 кӨннән китерегез* (принесите).

*— Ярый. Рәхмәт.*

*12. — Китапханәгә язылырга мӨмкинме?*

*— МӨмкин. Адресыгызны әйтегез.*

*— Казань-71, Ершов урамы, Өченче йорт, илленче квартир (фатир).*

*— Кайда эшлисез?*

*— Компрессор заводында.*

*— Кем булып?* (Кем?)

*— Инженер.*

*— Өйдә телефоныгыз бармы?*

*— Бар. 76-13-25.*

*— Эштә телефоныгыз бармы?*

*— Бар.76-25-43.*

*— Кул куегыз.* (Распишитесь.)

*— Хәзер.*

*— Рәхмәт. Булды* (Все). *Сезгә нинди китап кирәк?*

*— Миңа Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы кирәк.*

*— Юк шул. Кулда* (на руках). *Бер атнадан килегез. Алып куярмын* (приготовлю). *Тагын нәрсә кирәк?*

*— Сездә Дәрдемәнднең тәрҖемәләре бармы?*

*— Бик кечкенә бер китап бар.*

*— Бирегез әле.*

*— Хәзер. Менә.*

*— Рәхмәт Сезгә.*

*— Сау булыгыз. Тагын килегез.*

Теперь пойдем в киоск «Союзпечати» и будем покупать газеты и журналы.

*1. — «Казан утлары» журналы бармы?*

*— Бар.*

*— Бирегез әле.*

*— Мәгез. 5 сум.*

*— Рәхмәт.*

*2. — «Мирас» журналы бармы?*

*— Бар.*

*— Ничә сум?*

*— 5 сум.*

*— Миңа 2 журнал бирегез әле.*

*— Рәхим итегез.*

*3. — «Салават кҮпере» бармы?*

*— Бар. Рәхим итегез.*

*— Миңа 10 журнал кирәк.*

*— Ник* (почему?) *кҮп кирәк?*

*— Мин аны дусларымның балаларына Җибәрәм* (посылаю). *Рәхмәт.*

*4. — Сездә «Ялкын» журналы бармы?*

*— Юк, шул. Бетте* (кончился).

*— Гафу итегез, «Татарстан» журналы бармы сездә?*

*— Сезгә кайсы саны* (номер) *кирәк?*

*— Тугызынчы.*

*— Рәхим итегез.*

*— Рәхмәт.*

*5. — Исәнмесез!*

*— Исәнмесез!*

*— Миңа «Идел» Җурналы кирәк. Ул журнал русча чыгамы, татарча чыгамы?*

*— «Идел» журналы рус телендә дә, татар телендә дә чыга. Сезгә кайсы сан кирәк?*

*— Миңа унынчы сан кирәк.*

*— Татарча журнал кирәкме?*

*— Юк, русча журнал кирәк. Мин татарча начар* (плохо) *сӨйләшәм.*

*— Рәхим итегез!*

*— Рәхмәт Сезгә!*

*6. — Яңа газеталар бармы?*

*— Юк.*

*— Кайчан була?*

*— Бер сәгатьтән.*

*— Рәхмәт.*

*7. — «Ватаным Татарстан» газетасы юкмы?*

— *Бар.*

— *Яңамы?*

— *әйе.*

— *Миңа 2 газет бирегез әле.*

— *Рәхим итегез.*

— *Рәхмәт.*

*8. — «Татарстан яшьләре» килдеме?*

— *Юк әле.*

— *Кайчан була?*

— *БҮген булмый.*

— *Кызганыч* (Жаль).

*9. — Сездә «Юлдаш» бармы?*

— *Бар.*

— *Миңа 3 газет бирегез әле.*

— *Мәгез.*

— *Рәхмәт.*

*10. — БҮгенге* (сегодняшние) *газеталар бармы сездә?*

— *Сезгә нинди газета кирәк?*

— *Миңа «ДӨнья»* («Мир») *газеты кирәк. Ул латин әлифбасында* (алфавит) *чыга.*

— *әйе, беләм. Ул газета хәзер чыкмый.*

— *Кызганыч.*

*11. — Сез газетага язылдыгызмы әле?* (Подписались ли?)

— *Юк шул.*

— *Вакыт бар әле.*

— *Мин иртәгә язылам.*

— *ә мин язылдым. Мин «ШәҺри Казан» газетасына язылдым.*

*12. — Сездә район газеталары юкмы?*

— *Юк шул. Алар матбугат йортында бар.*

— *Рәхмәт сезгә.*

— *Сау булыгыз.*

*13. — Бу газета яңамы?*

— *Юк, иске.*

— *Миңа бҮгенге газета кирәк.*

— *Яңа газета юк шул.*

*14. — «Чаян» журналын укыдыңмы?*

— *әйе, укыдым.*

— *Аның мӨхәррире кем?*

— *Рәшит Зәкиев.*

— *«Чаян» русча чыгамы?*

— *әйе, русча да татарча да чыга.*

**Задание 1.** Продолжите диалоги.

а) — Миңа «Правда» кирәк иде.
— Юк шул...
б) — Сезгә «Идел» килдеме?
— Юк, ә синңа?...
в) — Мин быел «Чаян» журналы алам.
— Кызыкмы?...
г) — Син «Татарстан яшьләре» аласыңмы?
— Юк, мин татарча белмим. ә син? ...
д) — Иң кызыклы журнал нинди?
— Белмим. Минемчә, «Татарстан»...

БҮген без кҮп сӨйләштек.
Дәрес бетте.
Сау булыгыз!




# Урок двадцать пятый

(Егерме бишенче дәрес)

Исәнмесез!
Хәерле кӨннәр!
Продолжаем изучение глагольных времен.

### Давнопрошедшее время

Это время образуется добавлением к корню и основе глагола аффиксов **-ган иде/-гән иде** и **-кан иде/-кән иде**. Спрягается только последняя часть — вспомогательный глагол «**иде**». Это время выражает действия, давно уже прошедшие или предшествовавшие другому прошедшему действию.

**Единственное число**

| | | |
|---|---|---|
| *Мин бар-ган иде-м* | *әйт-кән иде-м* | (я ходил, говорил) |
| *Син бар-ган иде-ң* | *әйт-кән иде-ң* | (ты ходил, говорил) |
| *Ул бар-ган иде* | *әйт-кән иде* | (он ходил, говорил) |

**Множественное число**

| | | |
|---|---|---|
| *Без бар-ган иде-к* | *әйт-кән иде-к* | (мы ходили, говорили) |
| *Сез бар-ган иде-гез* | *әйт-кән иде-гез* | (вы ходили, говорили) |

| | | |
|---|---|---|
| *Алар бар-ган-нар иде* | *әйт-кән-нәр иде* | (они ходили, говорили) |

Поговорим по-татарски.

*1.— Мин театрга барган идем, сине кҮрмәдем.*

*— Мин бармадым. Мин авылга кайткан идем.*

*2. — Син миңа әйткән идең: Марат укырга кергән.*

*— әйе шул.*

*3. — Ул язган иде, ике кӨннән кайтам дип.* (*дип* букв. говоря, сказав)

*— Кайтмады шул.*

*— Кайчан кайта соң? (соң —* же*)*

*— Белмим бит.*

*4. — Без быел авылга кайткан идек. Авылда яңа мәктәп салганнар* (построили).

*— әйе. Без дә кайткан идек. КҮрдек. Бик матур мәктәп.*

*5. — Быел безнең студентлар колхозга барганнар иде.*

*— Кайсы авылга?*

*— Казанбашка.*

*— Яхшы эшләгәннәрме соң?*

*— Бик яхшы эшләгәннәр.*

*— Нинди эштә?*

*— Бәрәңге алганнар.*

*6. — АйгӨл, син теге китапны алган идеңме?*

*— әйе.*

*— Миңа бир әле.*

*— Мә, Сәрия апа.*

*— Рәхмәт, АйгӨл.*

А теперь переходим к заданиям.

**Задание 1.** Продолжите диалоги.

а) — Син теге атнада авылга кайткан идеңме?

— ______________________________

— ______________________________

— ______________________________

— ______________________________

— ______________________________

б) — Галия апа безгә кайчан килгән иде?

— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________

в) — Сез аларга Казан турында сӨйләгән идегезме?
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________

г) — Алар кичә урманга барганнар идеме?
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________
— ________________________________

**Задание 2.** Переведите на русский язык.

Без кичә урманга барган идек. КӨн матур иде. Без Өч сәгать йӨрдек. Урманда Җиләк кҮп иде. Без ике чиләк Җиләк Җыйдык. Җиләк бик тәмле иде. Өйгә сәгать биштә генә кайтып Җиттек. әни варенье кайнатты Һәм безгә бик зур рәхмәт әйтте.

**Задание 3.** Переведите на русский язык.

Мин бу киноны былтыр караган идем.
Син кичә концертка барган идеңме?
Ул май аенда Америкага барган иде.
Без Сабантуйга машина белән кайткан идек.
Сез бу китапны кайдан алган идегез?
Алар Казанга кайчан килгәннәр иде?

**Задание 4.** Ответьте на вопросы.

Алар кайчан кайтканнар?
Ул Хәсән Туфанны белгәнме?
Абый театрга киткәнме?
әниләр дачага кичә барганнармы?
әбиләр Сабантуйга кайсы авылга киткәннәр?
Малайлар бу машинаны кайда кҮргәннәр?

Алар Казан университетында кайчан укыганнар?
Ул президент белән кайчан очрашкан?
Кызлар стадионга кайчан киткәннәр?
Абыйлар авылдан кайчан килгәннәр?
әби Өчпочмакны кайчан пешергән?

**Задание 5.** Поставьте глагольные сказуемые в прошедшем категорическом времени.

Минем әтием заводта ----------.
Аның әнисе базарга -----------.
Синең абыең колледжда -------?
Безнең дуслар диңгезгә ял итәргә --------.
Сезнең апагыз МәскәҮдә -----------?
Аларның әтиләре университетта -----------.
Сез институтта -------------?

**Задание 6.** Проспрягайте следующие глаголы в настоящем времени в единственном и множественном числах. Составьте с ними предложения.

*Бар, яз, кил, кайт, әйт, сӨйлә, пешер, чык, эшлә, ал, кер, тҮлә.*

**Задание 7.** Составьте диалоги с этими глаголами.

**Задание 8.** Найдите в пословицах слова в местно-временном падеже. Переведите пословицы.

Берлектә — кӨч.
Татулыкта — бәрәкәт.
Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта.
Дуслык ашта тҮгел, эштә беленә.
Яхшылык Җирдә ятмый.
Акыл яшьтә тҮгел — башта.
Башыңда белем аз булса, аягыңа авырлык кҮп килә.

Завершаем наш урок. И на прощание опять пословицы.

*Кыскалыкта — осталык* [къыскъалыкъта осталыкъ]. — В краткости — мастерство.

*Телләр белгән — илләр белгән* [телләр белгән — илләр белгән] — Знающий языки — знает и страны.

*Изге кеше Идел кичкән* [изге кеше Идел кичкән]. — Святой человек переплывает Итиль (Волгу).

*Ватаны юк — Җыры юк сандугач* [–атаны йукъ — Җыры йукъ санду„ач]. — Человек без родины, что соловей без песни.

Сау булыгыз!

Сезгә уңышлар телим!




# Урок двадцать шестой

(Егерме алтынчы дәрес)

—Хәерле кич, дуслар!

— Исәнмесез!

Сегодня наш урок будет радостным и веселым. Наша тема — татарская кулинария.

**Татарская кухня**

Вспомним знакомые слова, познакомимся с новыми словами и запомним их.

*Аша* — ешь, кушай
*эч* — пей
*БҮген бала* ***елый да елый.*** — Сегодня ребенок плачет и плачет.

*Улым, син* ***ашадыңмы****?* — Сынок, ты поел?

*әлфия, бҮген дару* ***эчтеңме****?* — Альфия, сегодня пила лекарство?

*БҮген ял кӨне булганга озак* ***йокладык.*** — Так как сегодня был выходной, спали долго.

*Баланы* ***очкылык тота****, су бир әле.* — Ребенок икает, дай-ка воды.

*Малай* ***тӨчкерде.*** — Мальчик чихнул.

*Син минем Өчен* ***кайгырма.*** — Ты не горюй за меня.

*әни,* ***борчылма****, мин озак тормам.* — Мама, не беспокойся, я долго не буду.

**Задание 5.** Ответьте на вопросы в отрицательной форме.

1. — *Бу кызлар* ***кӨләләрме****?*

   — ...

2. — *Бу апа* ***елыймы****?*

   — ...

3. — *Сез бҮген ашханәдә* ***ашадыгызмы****?*

   — ...

4. — *әни, син бҮген дару* ***эчтеңме****?*

   — ...

5. — *әби, озак* ***йокладыңмы****?*

   — ...

6. — *Кызым, синең Өчен бик* ***борчылам****.*

   — ...

7. — *әнием энем Өчен бик* ***кайгыра****. Энем авырый.*

   — ...

6) **Глаголы мышления** употребляются в следующем контексте:

*Син ничек* ***уйлыйсың****? Ул кайтырмы?* — Как ты думаешь? Он вернется?

*Син мине* ***аңлыйсыңмы****?* — Ты понимаешь меня?

*Мин аны дус* ***саныйм****.* — Я считаю его другом.

**Задание 6.** Ответьте в утвердительной форме.

1. *— Син мине Һич* ***аңламыйсың****!*

*— ...*

2. *— Син безнең турыда* ***уйлыйсыңмы****?*

*— ...*

3. *— Алар мине дус* ***саныйлармы****?*

*— ...*

7) **Глаголы состояния, существования** примерно следующие:

*Теге китап бу шкафта* ***тора.*** *— Та книга находится в этом шкафу.*

*Балык суда* ***яши.*** *— Рыба живет в воде.*

*БҮре урманда* ***яши.*** *— Волк живет в лесу.*

*Син бҮген Өйдә* ***буласыңмы****? — Ты сегодня будешь дома?*

*әби диванда* ***утыра.*** *— Бабушка сидит на диване.*

*Син монда* ***утыр****! — Ты садись сюда!*

*Эт оясында* ***ята.*** *— Собака лежит в своей конуре.*

*Мин сезне бакчада* ***кӨтәрмен.*** *— Я подожду вас в саду.*

**Задание 7.** Ответьте на вопросы.

1. *— БҮре кайда яши?*

*— ...*

2. *— Альбом кайда тора?*

*— ...*

3. *— Иртәгә син кайда буласың?*

*— ...*

4. *— Син ничәнче рәткә утырасың?*

*—...*

5. *— Китап кайда ята?*

*— ...*

6. *— Ул мине кайда кӨтә?*

*— ...*

**Задание 8.** Переведите предложения на татарский язык.

Лось живет в лесу. Рыба живет в воде. Человек живет в доме. Ты будешь в библиотеке? Он будет дома? Дедушка сидит на стуле. Мама сидит на диване. Сядь на стул! Тетрадь лежит на столе. Карточка лежит в книге. Кошка лежит на кровати. Они

ждут нас. Жди меня на остановке. Нурия меня не ждала. Мы их долго ждали.

8) Не помешает вам знать и **глаголы зова и крика**:

*Мин сине **чакырдым**, син бармадың.* — Я тебя звала, ты не пошел.

*Хәмит, әни **чакыра**, әйдә, Өйгә керик.* — Хамит, мама зовет, пойдем домой.

***Кычкырма** миңа!* — Не кричи на меня!

*Кем **кычкыра** анда?* — Кто там кричит?

*Эт **Өрер** — бҮре йӨрер.* — Собака лает — волк ходит.

*Ишетәсеңме, безнең колын **кешни.*** — Слышишь, наш жеребенок ржет.

*Бала Үкереп **елый.*** — Ребенок ревмя ревет.

*КҮке **кычкыра.*** — Кукушка кукует.

*БҮре **улый.*** — Волк воет.

*Чыпчыклар **чыркылдый.*** — Воробьи чирикают.

*Сыер **мӨгри.*** — Корова мычит.

**Задание 9.** Продолжите рассказ.

*1. Кичә әтинең туган кӨне булды. Без кунаклар чакырдык...*

*2. Без зоопаркка бардык. Анда хайваннар, кошлар кҮп. Монда аю кычкыра...*

**Задание 10.** Поставьте глаголы в отрицательной форме (**-ма, -мә, -м**).

әйттем
сорадылар
беләсең
[illegible]лиләр
барачаклар
төшсәм
кисәргә
карый
ясалар
кайтамы
менерләр
тектегез
укы
сөйлә
еладык

**Задание 11.** С этими словами составьте диалоги.

Дәрес бетте. Сезгә сәламәтлек, уңышлар телим. Сау булыгыз!




# Урок сорок седьмой

(Кырык Җиденче дәрес)

Исәнмесез!
Хәерле кӨн!

Помните, мы говорили об инфинитиве с показателями **-рга/-ргә**, **-ырга/-ергә**, **-арга/-әргә**. Это — неспрягаемая форма глагола. Приведем один поэтический текст с этими формами глаголов.

*Дусларым бар*
*серләшергә.*
*Җиде ят бар*
*киңәшергә.*
*Дошманнар бар*
*кӨрәшергә.*
*Бу Җирем бар*
*эзләнергә.*
*Бер илем бар*
*тезләнергә.*
*Һәм йӨрәгем бар*
*чыдарга.*
*Башым — мәйданга*
*чыгарга:*
*серләшергә,*
*киңәшергә,*
*кӨрәшергә,*
*эзләнергә,*
*тезләнергә*
*Һәм чыдарга...*
**(Ренат Харис)**

Выделим незнакомые слова:

*серләшергә* — поговорить по душам*; Җиде ят* — чужие*; киңәшергә* — советоваться*; кӨрәшергә* — бороться*; эзләнергә* — искать, познавать*; тезләнергә* — преклонить колени*; чыдарга* — терпеть.

Теперь давайте попробуем перевести:

*У меня есть друзья,*
*чтобы поговорить по душам.*
*Есть чужие,*
*чтобы советоваться.*
*Есть враги,*
*чтобы бороться.*
*Есть у меня эта земля,*
*чтобы познавать.*
*Есть у меня Родина одна —*
*чтобы преклонить колени.*
*И есть сердце,*
*чтобы терпеть.*
*(Есть) голова у меня —*
*чтобы выйти на площадь:*
*поговорить по душам,*
*советоваться,*
*бороться,*
*познавать,*
*преклонить колени*
*и терпеть...*

Помните глаголы в будущем неопределенном времени: барырмын — бармам, кайтырмын — кайтмам? Прочитаем стихотворение Ш.Галиева, где много глаголов в таком времени в отрицательной форме:

*Миндәй сине беркем **яраталмас**;*
*Миндәй сине беркем **сагынмас**.*
*Миндәй сине беркем **иркәләмәс**,*
*Миндәй бҮтән кеше **табылмас**.*

*Синдәй мине беркем **якын кҮрмәс**,*

*Синдәй мине беркем* ***назламас,***
*Синдәй мине беркем* ***юксыналмас,***
*Синдәй бҮтән беркем* ***сызламас...*** **(ШәҮкәт Галиев)**

Выделим новые формы и слова.

Аффиксы **-дай/-дәй**, **-тай/-тәй** выражают уподобление:

*миндәй* — как я
*синдәй* — как ты
*беркем* — никто
*бҮтән* — больше (никто)

А теперь глаголы:

*яраталмас* — не сможет полюбить
*сагынмас* — не соскучится
*иркәләмәс* — не поласкает
*табылмас* — не найдется
*якын кҮрмәс* — не будет близким
*назламас* — не будет нежить
*юксыналмас* — не станет тосковать
*сызламас* — не будет кручиниться.

В положительном аспекте эти глаголы были бы таковы: *ярата алыр, якын кҮрер, сагыныр, назлар, иркәләр, юксыныр, табылыр, сызлар.*

Вы поняли, конечно, что эти стихи — о любви.

**Задание 1.** При помощи словаря постарайтесь перевести это стихотворение.

А на прощанье вам новые глаголы. Какие из них вы знаете, а какие для вас новые?

*оныт* — забудь
*уят* — разбуди
*елмай* — улыбнись
*сӨй* — люби
*таныш* — знакомься
*Үл* — умирай
*яшә* — живи
*эзлә* — ищи
*ян* — гори
*Үт* — проходи
*Җый* — собирай
*тҮз* — терпи
*юат* — утешай
*бҮл* — дели
*бетер* — заканчивай
*сагын* — скучай, тоскуй
*сиз* — чувствуй
*очраш* — встречайся

*бел* — знай
*сайла* — выбирай
*ку* — отгони
*Өйлән* — женись
*кияҮгә чык* — выходи замуж
*хәтерлә* — помни
*Үп* — целуй
*кочакла* — обними
*сӨен* — радуйся
*озат* — провожай
*каршыла* — встречай
*шатлан* — радуйся
*югалт* — теряй...
*юат* — утешай

**Задание 2.** Составьте предложения с этими глаголами.

**Задание 3.** Прочитайте правильно диалоги.

*1. — әни, мине уятырга онытма, яме! Без иртәгә походка барабыз.*

*— Ярар, улым, ярар, уятырмын. Онытмам.*

*2. — Кара әле, Артур! Тегендә бер кыз ничек матур елмая!*

*— Кайда, кайда?*

*— әнә, әнә, Һәрвакыт* (всегда) *елмаеп тора!*

*— ә-ә-ә, кҮрдем.Матур елмая!*

*3. — Сез таныштыгызмы?*

*— Юк, без таныш тҮгел. Таныштыр әле безне.*

*— Бу — Морат, бу — АйгӨл.*

*— Рәхмәт, мин бик □ат.*

*4. — Син газета укыдыңмы?*

*— Нәрсә булган?*

*— Бер йорт шартлаган* (взорвался). *Бик кҮп кешеләр Үлгән.*

*— Кайда?*

*— МәскәҮдә.*

*5. — Син элек кайда яшәдең?*

*— Без Үзбәкстанда яшәдек.*

*— Аннан соң?*

*— Аннары МәскәҮдә яшәдек. Хәзер Казанда яшибез.*

*6. — Бакчада карлыган кҮпме?*

*— КҮп.*

*— Җыйдыгызмы әле?*

*— Юк әле, Җыймадык. Ике кӨннән Җыябыз.*

*7. — Мин сине бик сагындым, ГҮзәл!*

*— Мин дә бик сагындым, Искәндәр.*

**8.** — Мин әнине бик сагындым.

— Мин дә сагындым. Бәйрәмгә кадәр ничек тҮзәргә инде? Бәйрәмгә кайтыр идек...

9. — Кичә урамда бер кыз бала белән очраштык. Аның курчагы (кукла) югалган. Ул елый, елый...

— Син аңа нәрсә дидең?

— Мин аны юаттым. Синең курчагың сиңа кайтыр, дидем.

**10.** — Эшең беттеме, әни? Базарга барабызмы?

— Хәзер бетә эшем. Менә савыт-сабаны юып бетерәм дә барырбыз.

— әни, Үзем юып бетерәм, яме!

— Ярый.

**11.** — Камил, кайда очрашабыз?

— Парк янында очрашыйк.

— Юк, анда кеше кҮп. Танышлар кҮп. әйдә, университет янында очрашабыз.

— Ярар. КӨтәм. Озак торма. Сәгать 6 да мин шунда булам.

**12.** — Егетләр, мин Өйләнәм!

— Ничек, кызны сайладыңмы инде?

— Сайладым инде кҮптән. Иң акыллы, иң матур, иң эшчән, иң бай, иң уңган, иң гҮзәл кызны сайладым.

— Кем ул?

— Нурия.

— О-о-о! Нурия сиңа кияҮгә чыгамы?

— ә нигә чыкмас икән?

— Аның егете бар бит...

**13.** — Камил, син берәр кызны Үптеңме?

— әйе, бер кӨнне бер кыз белән очраштык. Ул бик матур, акыллы кыз. Без аның белән 1 ел йӨрдек (дружили). Ул миңа рӨхсәт итте Үбәргә. Мин аны кочакладым Һәм битеннән Үптем...

14. — әбиемне бик сагындым. Авылга кайтсам, кочаклап Үбәм мин аны!

— Минем әбием Үзе мине кочаклый, Үзе Үбә.

— Кызык!

**15.** — Кызлар, мин конкурста беренче урын алдым!

— *СӨендеңме соң?*
— *Ни әйтергә дә белмим.*

16. — *Роза, иртәгә вокзалга сине озатырга киликме?*
— *Вакытыгыз булса килегез.*
— *Тагын кем килә сине озатырга?*
— *Рамил киләчәк.*
— *Шулаймыни? әллә без килмикме?*
— *Килегез, килегез. Без бик шатланып очрашырбыз.*

17. — *Бу китапны югалтырга ярамый.*
— *Ник?*
— *Ул бер генә китап. Аны Өйгә дә бирмиләр.*
— *Шулаймыни?!*

**Задание 4.** Постарайтесь сами составить предложения с этими глаголами в различных формах, которые вам знакомы. Употребите их в микродиалогах.

В татарском языке также много сложных предложений различной структуры. Сейчас мы ознакомимся с т.н. аналитическими предложениями, в которых употребляются подчинительные союзы (чөнки — потому что, әгәр — если, гәрчә — хотя и т.д.), относительные слова от корня **шул** — тот; такой (шуңа — тому, шуны — того, то, шунда — там, у того, шуңа карамастан — несмотря на, шул сәбәпле — по этой причине, шул вакытта — в то время и т.д.) и интонации ожидания и пояснения.

**Задание 5.** Переведите предложения.

1. Кем белә, шул әйтә
2. Кемне чакырам, шул бара.
3. Кемнән сорыйм, шул җавап бирә.
4. Кемгә әйтәсез, шулар килер.
5. Кемдә яңа дәреслек бар, шул китаптан укыгыз.
6. Бездә бер кыз эшли, шул кызның абыйсы — физик.
7. Бүген яңгыр, шуңа карамастан без гөмбә җыярга киттек.
8. Урамда 35 градус салкын, шуңа күрә балалар мәктәпкә бармадылар.
9. Дәрес бетәр, шул вакытта без синең белән сөйләшербез.
10. Син ничек әйтәсең, мин шулай эшләрмен.
11. Ул кая бара, син дә шунда бар.

12. Кызлар кайчан килсәләр, шунда син миңа шалтырат (позвони).
13. Җенат кайда була, мин дә шунда барам.
14. Син нәрсә яратсаң, мин дә шуны яратам.

Задание 6. Подобные предложения употребите в диалоге.

На сегодня все!
Сау булыгыз! Уңышлар телим.




# Урок сорок восьмой

(Кырык сигезенче дәрес)

Этот урок мы посвятим диалогам на темы: «Транспорт», «Почта, телефон, телеграф», «Отдых», «Печать», «Здоровье».

**ТРАНСПОРТ**

1. — *Гафу итегез, 5-нче трамвай кайда туктый?*
   — *Бакча янында.*
2. — *Гафу итегез, трамвай билеты ничә сум?*
   — *2 сум.*
3. — *Гафу итегез, алдагы тукталышта тӨшәсезме?*
   — *Нинди була?*
   — *Ирек мәйданы.*
   — *әйе, тӨшәбез.*
4. — *Гафу итегез, миңа берәр талон бирмәссезме?*
   — *Рәхим итегез.*
5. — *Гафу итегез, 1 пачка талон ничә сум?*
   — *20 сум.*
6. — *Гафу итегез, бу ничәнче автобус иде?*
   — *Илле алтынчы.*
   — *Ай, Өлгермәдек.*
7. — *Гафу итегез, автовокзалга ничек барырга?*
   — *2-нче троллейбус белән.*

*— ә ул кайда туктый?*

*— әбҖәлилов тукталышында.*

*— Озак барасымы?*

*— 9-нчы тукталышта тӨшегез. Сул якта автовокзал булыр.*

*— Рәхмәт Сезгә.*

*— Берни тҮгел.*

## ПОЧТА. ТЕЛЕФОН. ТЕЛЕГРАФ.

1\. *— Кичә миңа әнидән хат килде.*

*— Нәрсә яза?*

*— Тизрәк кайт, ди. Урманда Җиләк кҮп, ди.*

*— Кайтасыңмы соң?*

*— Ике кӨннән.*

2\. *— Сезнең адресыгыз нинди?*

*— Казан, Тукай урамы, 14 йорт, 2-нче квартира.*

3\. *— Сез хат ташучымы?*

*— әйе.*

*— Миңа бҮген хат юкмы?*

*— Юк шул.*

4\. *— Гафу итегез, почта кайда микән?*

*— Бер квартал барасы бар.*

5\. *— Телеграмма бланклары бирегез әле.*

*— Мәгез* (Ӏозьмите).

*— Рәхмәт.*

6\. *— Сезгә телеграмма.*

*— Каян?*

*— МәскәҮдән.*

*— Рәхмәт.*

7\. *— Миңа 5 конверт бирегез әле.*

*— Мәгез. 10 сум бирегез.*

*— Рәхмәт.*

8\. *— Миңа хат юкмы?*

*— Паспортыгызны бирегез.*

*— Мәгез.*

*— Хәзер карыйм. Бар. Хәтта ике.*

*— Рәхмәт Сезгә.*

*9. — Варшава белән сӨйләшергә заказ кабул итегез әле?*
*— Рәхим итегез.*

## ОТДЫХ (ЯЛ ИТҮ)

*1. — Син ничек ял итәсең?*
*— Укыйм, кинога, театрга йӨрим.*
*— ә син?*
*— Мин урманга барырга, Җиләк, гӨмбә Җыярга яратам.*
*2. — Син музыка яратасыңмы?*
*— Яратам.*
*— Ниндине?*
*— Халык кӨйләрен. ә син?*
*— ә мин заманча музыка яратам.*
*3. — Су коенырга барабызмы?*
*— Кая?*
*— Зәңгәр кҮлгә.*
*— Анда ничек барырга?*
*— Автобус белән.*
*— Озакмы?*
*— Бер сәгать.*
*— Ой-ой, озак икән. әллә Казансуга гына тӨшәбезме?*
*— Аның суы бик әйбәт тҮгел шул.*
*4. — Алсу, Сезне иртәгә театрга чакырам. Барасызмы?*
*— Бик рәхәтләнеп. ә нәрсә карыйбыз?*
*— Аяз ГыйләҖевнең «Өч аршын Җир» исемле спектаклен.*
*— Ярый. Кайда очрашабыз?*
*— Театр каршында, Җиде туларга унбиш минут кала.*
*— Ярый, мин килермен.*
*— Рәхмәт, мин сине кӨтәрмен.*
*5. — Син спорт белән шӨгыльләнәсеңме?*
*— әйе, мин теннис уйнарга яратам. ә син?*
*— Мин баскетбол уйныйм.*
*— Ярышларда катнашасыңмы?*
*— әйе, безнең команда шәҺәрдә беренче урында.*
*6. — Бу команданың тренеры кем микән?*
*— Гайнуллин Рәхим Булатович.*

*— Ул спорт мастерымы?*

*— әйе.*

7. *— Гафу итегез, уен кайчан башланды?*

*— Ун минут элек.*

*— Кем Җиңә?*

*— әле беркем дә Җиңми.*

8. *— Татарларда нинди милли спорт тӨрләре бар?*

*— Иң яхшысы — татарча кӨрәш.*

*— Тагын?*

*— Ат чабышлары.*

*— Тагын?*

*— Мин бик Үк белеп Җиткермим шул.*

9. *— Сездә сабантуй ничек була?*

*— Бик кызыклы була.*

*— СӨйлә әле.*

*— Берничә кӨн кала Өйдән Өйгә йӨреп, яшь киленнәрдән чиккән сӨлгеләр, бҮләкләр Җыеп йӨриләр. Сабан туе су буендагы болында була. Анда башта балалар, аннан соң Үсмерләр кӨрәшә. Соңыннан чират иң кӨчлеләргә Җитә. Сабантуйның иң кӨчле батырына я сарык, я келәм, я мотоцикл бирәләр.*

*— Ат чабышлары буламы?*

*— Була. Бик кҮңелле була.*

*— Капчык белән бҮрәнә Өстендә дә сугышалармы?*

*— әйе.*

*— Кашыкка йомырка утыртып та йӨгерәләрме?*

*— әйе. Сездә дә шулаймыни?*

*— әйе. Бездә әле колгага* (столб) *да менәләр.*

*— Бездә дә шулай. Колга башында я әтәч, я итекләр, я башка бер әйбер була.*

*— Җырлыйлармы?*

*— Җырлыйлар да, бииләр дә, гармун да уйныйлар.*

*— Сабантуйга кунаклар кайтамы?*

*— Бик кҮп кайталар. Бик ерак Җирләрдән кайталар. Алар читтә тальян моңына, халык кӨйләренә, авыл ашларына сусап* (скучая) *яшиләр дә, кҮңелләренә рухи ләззәт алып китәләр.*

*— Синең Казан сабантуйларында булганың бармы?*

*— Бар. Ләкин авылныкы кҮбрәк ошый миңа.*

*— Миңа да.*

## ПЕЧАТЬ (МАТБУГАТ)

1\. *— Миңа «Салават кҮпере» журналы кирәк иде.*

*— Бездә бетте шул. Икенче киоскыдан сорап карагыз.*

*— Рәхмәт.*

2\. *— Син нинди газеталарга язылдың?*

*— «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Вечерняя Казань».*

*— Журналлар аласыңмы?*

*— әйе. Безгә «Казан утлары», «СӨембикә», «Идел» журналлары килә.*

3\. *— Син кичәге «Ватаным Татарстан» гәзитен укыдыңмы?*

*— Юк әле. Нәрсә бар?*

*— Президентның бер бик кызыклы мәкаләсе басылган.*

*— Укырмын. әйтҮеңә рәхмәт.*

4\. *— Татар теленең ҮзӨйрәткечен кайда саталар микән?*

*— Бауман урамындагы китап кибетендә.*

*— Син алдыңмы?*

*— Алдым.*

5\. *— Син кайсы шагыйрьләрнең иҖатын яратасың?*

*— Миңа Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким шигырьләре ошый.*

*— ә сиңа?*

*— Мин яшьрәк шагыйрьләрне яратам.*

*— Кемнәрне?*

*— Р.Фәйзуллинны, Х.әюповны, Рәшит әхмәтҖановны, ЗӨлфәтне, М.ә»ләмовны.*

*— Синдә аларның китаплары бармы?*

*— Бар.*

*— Миңа да биреп торырсың әле.*

*— Ярый. Бирермен.*

## ЗДОРОВЬЕ (СәЛАМәТЛЕК)

1. — *Нигәдер башым авырта.*

— *Баш даруы биримме соң?*

— *Бармы?*

— *Бар.*

— *Бир әле. Су да бир.*

— *Мә.*

— *Рәхмәт сиңа.*

2. — *Ай! Кулым киселде!*

— *Кая, нәрсә бирим?*

— *Йод белән мамык* (вата) *бир әле.*

— *Менә. Хәзер каны туктар.*

— *Рәхмәт сиңа.*

3. — *Безнең апа больницада ята бит әле.*

— *Ни булган?*

— *Ашказаны* (җелудок) *авырта ди.*

— *КҮптән ятамы?*

— *2 атна инде.*

— *Хәле ничек соң?*

— *Бераз Җиңеләя инде.*

4. — *Миңа ютәл* (кӑель) *даруы кирәк иде. Рецепт язып бирегез әле.*

— *Хәзер.*

— *Рәхмәт сезгә.*

5. — *Иптәшегезгә операция ясадылармы?*

— *әйе. Кичә ясадылар.*

— *Хәле ничек?*

— *Бик Үк Җиңел тҮгел әле.*

— *Сезгә бирәр ярдәм кирәкмиме?*

— *Юк, рәхмәт Сезгә.*

6. — *Мин быел бер дә авырмадым.*

— *Ничек алай?*

— *Кыш буе чаңгыда шудым, урамда кҮп ҖәяҮ йӨрдем, бассейнга йӨзәргә йӨрдем, кӨн саен зарядка ясадым.*

— *Вакытың кҮп булган икән!*

— *Вакыт кҮп тҮгел, авырыйсы килми. Сине дә Үзем белән алып бара алам.*

— *Ай, рәхмәт әйтҮеңә. Мин дә синең белән йӨрим әле.*

— *әйдә.*

*7. — Сез кайсы табибка (врачка) чират алдыгыз?*

*— Мин — Венера Хафизовнага.*

*— Мин дә шуңа. И, әйбәт тә врач инде ул, әйеме?*

*— әйе. Ул шундый и»тибарлы, ачык йӨзле, ярдәмчел, ихлас кҮңелдән ярдәм итәргә тели. Аны яратмаган кеше юктыр безнең авырулар арасында.*

*— әйе шул.*

*8. — Врач Хәкимова кайда кабул итә?*

*— 41-нче бҮлмәдә.*

*— Чиратта кем соңгы?*

*— Мин.*

*— Мин сезнең арттан.*

*— Ярый.*

*9. — ФәйрҮзә, безнең оныгыбыз бар бит.*

*— Кайчан туды?*

*— БҮген генә. Иртән.*

*— әнисенең хәле ничек?*

*— әйбәт. СӨте дә бар.*

*— Бала сәламәтме?*

*— әйе, зур ди. 4 кило да 800.*

*— Ай-яй, зур! Сәламәт булып Үссен.*

*— әйе, шулай булсын инде. Ярый, минем алар янына барасым бар. Ашарга илтәм. Сау бул.*

*— Сәлам әйт. Мин дә барырмын әле. Кайсы хастаханәдә (больницада)?*

*— Тимер юлчылар больницасында.*

*— Рәхмәт. Сау бул.*

**Задание 1**. Поставьте к данным словам антонимы:

| | |
|---|---|
| бар — | ана — |
| бир — | аз — |
| кайт — | дус — |
| кит — | якын — |
| ят — | монда — |
| тө˝ — | зур — |
| эти — | сәламәт — |

**Задание 2.** С этими словами составьте диалоги.

Дәрес бетте. Сау булыгыз. Сезгә уңышлар телим.




# Урок сорок девятый

(Кырык тугызынчы дәрес)

— Исәнмесез!

— Хәерле кич, кадерле дуслар!

Сегодняшний урок мы проведем несколько своеобразно. Это будет некоторым обобщением того, что вам уже знакомо и известно. Попробуем прочитать и понимать отдельные маленькие монологические тексты.

Давайте начнем с самого простого.

*БҮген, 27 февральдә, явымсыз, алмашынучан болытлы Һава. Казанда 7-9, Татарстанда 6-11 градус салкын.*

*Алдагы ике кӨндә болытлы Һава. Температура тӨнлә 14-19 (урыны белән 25 градуска кадәр), кӨндез 6-11 градус салкын булачак.*

В этом отрывке многие слова вам понятны. Но есть, наверное, и новые: *явымсыз* — без осадков; *алмашынучан болытлы Һава* — переменная облачность; *алдагы* — предстоящий; *урыны белән* — местами.

Попробуем текст посложнее.

***«ИнҖил» Үзбәк телендә***

*Моннан бер ел элек изге Коръән Үзбәк теленә тәрҖемә итеп бастырылган иде. әле кҮптән тҮгел «ИнҖил» (Библия) Үзбәкчә басылып чыкты. Тиражы — 50 мең данә. Аны Стокгольмның «ИнҖил»не ТәрҖемә итҮ институты әзерләгән. Институтның бҮлек мӨдире белдергәнчә, бу китап Өстендә тәрҖемәчеләр 20 ел эшләгән («Татарстан хәбәрләре», 27 февраль, 1993).*

Попробуем сами перевести этот текст. Он содержит слова, которые мы уже проходили. Дадим перевод нескольких слов: *изге* — священный, *бастырылган иде* — был издан, *данә* — экземпляр, *әзерләгән* — подготовил, *бҮлек мӨдире* — заведующий отделом, *белдергәнчә* — как заявил.

Еще одна проверка. Прочтите текст. Все ли слова понятны?

***Җәй кӨне***

*Җәй кӨне без урманда ял итәбез. Иртә белән су коенабыз. КӨндез урманда йӨрибез. Алмаз балык тота. Ләйлә шифалы Үләннәр Җыя. Абый Үләннәрдән гербарий әзерли. әни белән мин Җиләк Җыям. әти — урман каравылчысы. Ул кӨне буе урманда йӨри. Кич белән без бергә Җыелып, ашыйбыз, чәй эчәбез, кош сайраганын тыңлыйбыз.*

Поняли ли текст? Наверное, вам непонятны были следующие слова: *су коенабыз* — купаемся; *шифалы Үлән* — лекарственное растение; *каравылчы* — сторож; *сайраганын* — как поет.

Теперь задание будет посложнее. Прочтите знаменитое стихотворение Г.Тукая «Родной язык» (1910). Это — и прекрасная песня, которая превратилась в гимн татарского народа. И нет человека, который бы не знал её.

**Туган тел**

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*ДӨньяда кҮп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*

*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә кӨйләгән,*
*Аннары тӨннәр буе әбкәм хикәят сӨйләгән.*

*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*

*И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам.*
*Ярлыкагыл дип Үземне, әткәм-әнкәмне, ходам!*

*(Г.Тукай)*

Прочитали? Давайте вместе постараемся перевести непонятные слова: *туган тел* — родной язык; *әткәм-әнкәм* — отец мой — мать моя (родители), *дӨньяда* — на свете; *аркылы* — через; *иң элек* — прежде всего; *бишектә* — в колыбели; *кӨйләгән* — напевала; *аннары* — затем; *тӨннәр буе* — ночами; *әбкәм* — бабушка моя; *хикәят* — рассказы (сказки); *сӨйләгән* — рассказывала; *Һәрвакытта* — всегда; *ярдәмең бе(р)лән* — с помощью твоей; *аңлашылган* — ставший понятным; *шатлыгым* — радость моя; *кайгым* — горе мое; *кылган догам* — прочитанная молитва моя; *ярлыкагыл* — прости; *дип* — говоря; *ходам* — аллах мой.

А теперь приведем литературный перевод этого стихотворения, выполненный Р.Бухаревым.

**Родной язык**

*О язык, родной, певучий! О родительская речь!*
*Что еще на свете знал я, что сумел я уберечь?*

*Колыбель мою качая, тихо-тихо пела мать,*
*Подрастая, сказки бабушки, я начал понимать...*

*О язык мой, мы навечно неразлучные друзья, —*
*С детства стала мне понятна радость и печаль твоя.*

*О язык мой! Как сердечно я молился в первый раз:*
*Помоги, — шептал, — помилуй мать с отцом, помилуй нас...*

Давайте посмотрим другое стихотворение. Там, наверное, почти и не будет незнакомых вам слов. Это стихотворение Х.Аюпова, на слова которого Луиза Батыр-Булгари написала

музыку. Называется оно «Сиңа гына язган хатлар» («Только тебе написанные письма»)

әгәр еракларга китеп барсам,
Сагынудан синдә янса утлар —
Бәхет тамчылары булып тамар
Сиңа гына язган назлы хатлар.

Чәчләреңә инде чал керсә дә,
Искә тӨшәр бергә булган чаклар.
Яшьлек тургайлары булып килер
Сиңа гына язган назлы хатлар.

ЙӨрәкләрдә янган сӨю утын
СҮрелдерми мәңге шулай сакла —
Син кӨт кенә, килер сагынганда
Сиңа гына язган назлы хатлар...

**ˈадание 1.** Постарайтесь понять и перевести это стихотворение с помощью татарско-русского словаря.

* * *

Еще один текст о выпускниках одной школы.

**Бер класстан сигез медальче**

*Нижгар. Үткән ел Уразавыл мәктәбен 41 укучы тәмамлаган, шуларның сигезе укуларын алтын һәм кӨмеш медальләргә бетергәннәр. Бу хәл мәктәп тарихында беренче мәртәбә булган. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаучылардан ГӨлнара әхмәтбаева хәзер МәскәҮ экология-политология университетында, ГҮзәл МӨхәммәтҖанова Россия дәҮләт медицина институтында, Ләйлә Мостафина Казан дәҮләт университетының журналистика факультетында, ГҮзәл Шәймарданова Нижгар промышленность һәм экономика техникумында укыйлар.*

*әлбәттә, укучыларның шулай яхшы укуында мӨгаллимнәрнең дә Өлеше зур. Хәзер Уразавыл мәктәбендә 50 укытучы 550 балага сабак бирә. Унике укытучы «Халык*

*мәгарифе отличнигы» исеменә лаек булганнар, ә математика укытучысы Е.Аляутдиновага «РСФСРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелгән. (К.Фәйзуллин. — «Татарстан хәбәрләре», 25 февраль 1993 ел).*

В этом тексте, вероятно, незнакомыми вам словами окажутся: *Нижгар* — Нижний Новгород, *мәртәбә* — раз, *мӨгаллимнәрнең* — учителей, *Өлеш* — доля, *сабак бирә* — дает уроки, *мәгариф* — образование, *лаек булганнар* — удостоились, *атказанган* — заслуженный, *мактаулы* — почетный.

Еще раз прочтите текст. Теперь текст станет более понятным для вас.

Ознакомимся еще с одной информацией из газеты.

## Татар ашын тансыклаганнар

*Саба. Шәмәрдән урта мәктәбенең 6 сыйныф укучысы Зилә Зарипова, 7 сыйныфтан Мәдинә әпсәләмова Һәм 10 сыйныфтан АйгӨл Нурисламова быелгы уку елында ТӨркиядә белем алалар.*

*Алар кҮптән тҮгел Шәмәрдәнгә кайтып киттеләр. ТӨркиядә белем алучы элеккеге укучыларыбыз мәктәптә укытучылар Һәм иптәшләре белән очраштылар.*

*Үткән ел август ахырында Казаннан киткәч, алар әҮвәл Истанбулга килеп тӨштеләр. Аннан әнкарага юл тоттылар. Шунда бер ай тӨрек телен Өйрәнәләр. Шуннан соң Истанбулга кайтып укый башлыйлар, тӨрек, гарәп Һәм инглиз телләрен Өйрәнәләр.*

*КҮптән тҮгел кызлар ТӨркиягә киттеләр. Алар хәзер укуларын, яшь Үзенчәлекләренә карап, инглиз телендә тӨрле лицейларда дәвам итәчәкләр.*

*Иптәшләре белән хушлашканда, кызлар әти-әниләрен, туганнарын, иптәшләрен, укытучыларын, туган Шәмәрдән тӨбәген сагынуларын, татар милли ашларын тансыклауларын тагын бер кат искә алдылар.*

*(Р.Кашапов «Татарстан хәбәрләре», 26 февраль, 1993 ел).*

В этом тексте много слов, знакомых вам. Текст вы поняли, но отдельные слова, наверное, остались непонятными. Возмож-

но, вот эти: *тансыклаганнар* — соскучились, захотелось куˮать; *быелгы* — нынешний, *белем алалар* — получают знания, *элекке* — бывшие, *Үткән* — прошлый, *ахырында* — в конце, *әҮвәл* — вначале, *юл тоталар* — держат путь, *шуннан соң* — после этого, *кҮптән тҮгел* — недавно, *яшь Үзенчәлекләре* — возрастные особенности, *карап* — (букв. глядя, смотря), *дәвам итәчәкләр* — будут продолжать, *хушлашканда* — когда прощались, *тӨбәген* — местность (в вин. падеже с аффиксом принадлежности), *сагынуларын* — как они тоскуют, *милли* — национальный, *тагын* — еще, *искә алдылар* — вспоминали.

Вот, кажется, все трудные слова позади. Еще раз прочтите текст, проверьте свои знания. Вспомните времена глаголов — они имеются в тексте, переведите их правильно.

На этом завершаем наш урок.

Сау булыгыз! Сезгә исәнлек-иминлек (здоровья и благополучия) телим. Зур уңышлар сезгә!




# Урок пятидесятый

(Илленче дәрес)

— Исәнмесез!

— Хәерле кӨн, хӨрмәтле дуслар!

Сегодня мы познакомимся с вводными словами и сочетаниями.

## Вводные слова

В татарском языке широко употребляются многочисленные вводные слова, выражающие отношение говорящего к высказываемой мысли и к действительности. Они являются исконными или заимствованы из арабского и персидского языков, скалькированы с русского языка. Ознакомимся с наиболее широко употребительными из них.

***әлбәттә*** (конечно) — выражает достоверность, согласие, утверждение.

*1. — Син барасыңмы?*
*— әлбәттә, барам.*

*2. — Гариф абый бу турыда беләме?*
*— әлбәттә.*

*3. — Син, әлбәттә, оныттың инде?*
*— Гафу итегез, оныттым шул.*

***Ахрысы, ахры*** (видимо), ***бәлки*** (может быть), ***никтер*** (почему-то), ***кҮрәсең*** (видно), ***шәт*** (вероятно), ***ихтимал*** (возможно) — выражают неуверенность, недостоверность:

*1.— Без сезне кӨттек, кӨттек. Сез,* ***ахрысы,*** *килмәдегез.*

*— Без трамвай тукталышында озак басып тордык. Трамвай килмәде. ЖәяҮ бардык. Сез киткән идегез инде.*

*2. —* ***КҮрәсең,*** *бҮген концерт булмый. Клубта бер кеше дә юк бит.*

*— Концерт була. әле сәгать 5 кенә бит. Бераз кӨтеп торыйк.*

*—Ярар.*

*3. —* ***Ихтимал,*** *Рәис Солтанович белмәгәндер.*

*— Белсә, ул чыгыш ясаган булыр иде.*

*— Сез аңа әйтмәдегезмени?*

*— Мин аны кҮрмәдем шул.*

*4. — БҮген,* ***никтер,*** *башым авырта.*

*— БҮген атмосфера басымы бик тҮбән.*

*— Белмим шул. Синең баш даруы юкмы?*

*— Бар. Менә.*

*— Рәхмәт сиңа.*

*5. — Иптәшләр, кем сӨйли?*

*— СӨйләҮчеләр юк.*

*—* ***Бәлки,*** *Сания апа, сез сӨйләрсез?*

*— Ярар, бер-ике сҮз әйтим.*

*— Рәхим итегез. СҮз Сания ханым Галиуллинага бирелә.*

Вводное слово ***зинһар*** (пожалуйста) выражает убедительную просьбу:

*1. —* ***Зинһар,*** *таралышмагыз. Хәзер Җыелыш була.*

*— Нинди Җыелыш?*

*— Акционерлар Җыелышы.*

*— Озак буламы?*

*— Ярты сәгать.*

*— Ярар, алайса, калабыз.*

*2. — Рәзинә,* ***зинһар,*** *миңа бҮген булыш әле. Безгә кунаклар килә.*

*— Кайчан килим, апа?*

*— Бер сәгатьтән килә аласыңмы?*

*— Килә алам.*

*— Мин сине кӨтәм.* ***ЗинҺар****, кил, яме.*

*— Ярар, апа.*

Вводные слова ***минемчә*** (по-моему), ***синеңчә*** (по-твоему), ***безнеңчә*** (по-нашему) выражают источник данного сообщения и отношение говорящего к происходящему:

1. — ***Минемчә****, концерт бик матур булды.*

*— ә* ***минемчә****, нәрсәдер Җитмәде.*

*—* ***Минемчә****, концертны алып баручы оста тҮгел иде.*

*2. —* ***Синеңчә****, Рәиф нишләргә тиеш?*

*— Гафу Үтенергә тиеш.*

*— Ул гаепле тҮгел бит!*

*—* ***Минемчә****, ул гаепле.*

*3. —* ***Минемчә****, сез ялгышасыз.*

*— Минме?* ***Гафу итегез****, мин ул кешене бик яхшы беләм. Мин аның белән 20 ел эшләдем бит.*

Вводное слово ***ниҺаять*** (наконец) употребляется для выражения процесса, который наконец совершился.

*1. —* ***НиҺаять****, бу китапны язып бетердем.*

*— Озак яздыңмы?*

*— Озак, 2 ел.*

*2. —* ***НиҺаять****, мин виза алдым. Иртәгә ТӨркиягә очабыз.*

*— Ничә кӨнгә?*

*— Ике атнага.*

*3.— Улым,* ***ниҺаять****, университетны тәмамлады.*

*— Ник «ниҺаять» дисең?*

*— Озак укыды. Беренче курстан соң армиягә китте. Анда ике ел хезмәт итте. Кайткач, икенче курска керде. Менә быел гына бетерде.*

*— Тәбрик итәм.*

*— Рәхмәт.*

Вводные слова ***беренчедән*** (во-первых), ***икенчедән*** (во-вторых), ***Өченчедән*** (в-третьих) выражают порядок перечисления фактов:

*1. — Сания, син ничек уйлыйсың?*

*— **Беренчедән**, мин ул кешене белмим.*

*— **Икенчедән**?*

*— **Икенчедән**, мин бит Үзем дә пенсиядә.*

*— **Өченчедән**?*

*— **Өченчедән**, минем дә балаларым бар.*

*2. — Балалар, әйдәгез әле, бу малайның тәртибен тикшерик. әйдә, Рәсим, син әйт.*

*— **Беренчедән**, РӨстәм безне алдаган. **Икенчедән**, РӨстәм Өй эшен эшләмәгән. **Өченчедән**, ул дәфтәрендәге «икеле» билгесен бетергән...*

Вводное слово ***димәк*** (значит) выражает умозаключение, обобщение:

*1. — Равия, син безгә юбилейга килмәдең. **Димәк**, син безне яратмыйсың.*

*— Юк инде, Солтания апа. Мин сезне бик яратам. Мин икенче сменада эштә идем шул. Гафу итегез инде.*

*2. — Монда ике мең ярым гына акча бар.*

*— Кая киткән соң аның биш йӨзе?*

*— Белмим шул. **Димәк**, мин ялгышканмын...*

*3. — Бакчада колорадо коңгызы кҮренә башлады.*

*— **Димәк**, быел бәрәңге булмый инде.*

*4. — РӨстәм, син яхшы укыйсыңмы?*

*— әйе, минем барлык фәннәрдән бишле генә.*

*— **Димәк**, син алтын медаль алачаксың.*

*— Белмим әле. Алда имтиханнар бик кҮп.*

*— Сиңа уңышлар телим.*

Вводное слово ***гадәттә*** (обычно) выражает известность, общепринятость данного сообщения:

1. *— Равил абый, **гадәттә**, халык Җырларын Җырлый.*

*— Каян беләсең?*

*— Мин аларда бик кҮп кунакта булдым. Ул Үзе баянда уйный, Үзе Җырлый.*

*— Матур Җырлыймы?*

*— Бик моңлы Җырлый.*

*2. — Театрга барганда, мин, **гадәттә**, кара кҮлмәк, кара тҮфли киям.*

*— Мин, **гадәттә**, Үземнең теге кҮк костюмымны киям.*

*— Нинди костюм, яңамы?*

*— Яңа тҮгел инде. Син беләсең аны.*

*— ә-ә-ә, син аны Петербургтан алып кайткан идең.*

*— әйе шул!*

*3. — Сабантуйга, **гадәттә**, без барыбыз бергә Җыелып авылга кайтабыз.*

*— ә без, **гадәттә**, ял паркына барабыз. Анда да сабантуй була.*

*— ә без, **гадәттә**, Арча поездына утырып, Арчага кайтабыз. Анда сабантуй бик кҮңелле була.*

*— Икенче елга мине дә алыгыз әле. Минем кҮптән авыл сабантуе кҮргәнем юк.*

*— Ярар. әйтербез.*

Вводное слово ***киресенчә*** (наоборот) выражает противопоставление:

*1. — Болай ярамый, иптәшләр!*

*— **Киресенчә**, нәкъ шулай кирәк.*

*2. — Мин моны әйтмәскә тиеш!*

*— **Киресенчә**, син әйтергә тиеш!*

*— Юк, юк, әйтмим!*

*3. — Җитте, бҮген мин анда бармыйм!*

*— Юк, **киресенчә**, син анда барырга тиеш. Син аңа аңлатырга тиеш. Ул сине аңлар. Мин ышанам.*

*— Рәхмәт киңәшеңә.*

Вводное слово ***гомумән*** (вообще) выражает обобщение:

*1. — **Гомумән**, бу мәсьәлә әзер тҮгел.*

*— **Минемчә**, уйларга кирәк.*

*2. — Мин сине, **гомумән**, аңламыйм.*

*— Ничек аңламыйсың?*

*— Аңламыйм шул. Кичә син болай сӨйләдең. БҮген — тегеләй* (по-другому).

*3. — Сез, **гомумән**, бу проблеманы хәл итәргә мӨмкин дип уйлыйсызмы?*

— ***Минемчә***, *мӨмкин.*

Вводное слово ***мәсәлән*** (например) особенно часто употребляется при перечислении, в учебниках:

*1. — Мин, **мәсәлән**, болай уйлыйм: сез безгә киләсез, аннан соң бергәләп вокзалга тӨшәбез дә поезд кӨтәбез.*

*— Ярар, мин риза.*

*2. — Укучылар, мин сҮзләр әйтәм. Сез ул сҮзләрне тәрҖемә итегез. **Мәсәлән**, су* — вода, *Җир* — земля, *кҮк* — небо. *Аңладыгызмы?*

*— Аңладык, ГҮзәлия апа.*

*3. — Балалар, әйдәгез, саныйбыз. Ләкин болай саныйбыз: 1, 3, 5, 7... **Мәсәлән**, Лена 1 ди, Саша 3 ди. АйгӨл 5 ди. Айдар 7 ди. Аңладыгызмы? әйдә, Лена, башла.*

*— Мин русча әйтимме?*

*— Юк, Лена, татарча саныйбыз.*

Вводное слово ***дӨрес*** (правда) выражает подтверждение факта, некоторую уступку, признание:

1. — ***ДӨрес***, *мин укымадым. Ләкин мин лекцияләргә йӨрдем.*

*— Сез бит материалны белмисез. Тагын бер тапкыр укып килегез.*

*— Кайчан килим?*

*— Өч кӨннән.*

*— Ярый. Сау булыгыз.*

*2. — Мин кичә вокзалга бардым бит. **ДӨрес**, мин унбиш минутка соңга калдым. Транспорт юк иде.*

*— Мин сезне кӨттем дә таксига утырып, кунакханәгә (гостиницага) киттем.*

— ***Кызганыч***, *гафу итегез.*

*3. — Сез, **дӨрес**, яхшы спортчы. Ләкин лекцияләргә йӨрмәдегез. Практик дәресләрдә булмадыгыз. КҮп нәрсәләрне белмисез. Сез бит математика укытучысы булачаксыз, физкультура укытучысы тҮгел. Мин сезгә Өчле куя алмыйм.*

*— Куегыз инде!*

*— Юк, тагын килегез.*

*4. — **ДӨрес**, ул соңыннан килде. Гафу Үтенде.*

*— Син гафу иттеңме соң?*

*— Юк, гафу итмәдем.*

Вводные слова ***тукта әле*** (постой-ка), ***кара әле*** (смотри-ка), ***беләсең килсә*** (если хочешь знать) и другие служат для привлечения внимания собеседника.

*1.— **Кара әле**, ишеттеңме: Данияр Өйләнгән.*
*— Кайсы Данияр?*
*— Безнең белән икенче цехта эшләгән иде.*
*— әйе, беләм. Кемгә Өйләнгән?*
*— Бер студент кызга.*
*2. — **Тукта әле**, Гайния апа, син нәрсә сӨйлисең?*
*— Миңа бу сҮзне МиңнегӨл әби әйтте.*
*— ә ул каян ишеткән?*
*— Кызлары әйткән.*
*— Алай икән!*
*3. — Алмаз безнең авылда туган.*
*— **Беләсең килсә**, Алмаз безнең авылда туган.*
*— Шулаймыни?*
*— әйе шул.*
*4. — Кара инде, нинди зур Үскән бу малай!*
*— әйе шул. Айдарга Өч яшь инде.*
*— Тукта әле, ул, **чыннан да**, без Казанда чакта туган иде.*
*— Шулай шул.*

Вводные слова ***имеш*** (дескать), ***янәсе*** (будто), ***ичмасам*** (даже), ***валлаһи, билләһи*** (ей-богу) — более разговорного характера:

*1. — Быел сабантуйда, **валлаһи**, батыр калам.*
*— Алла боерса диген* (Скаჟи, если бог даст).
*2. — **Ичмасам**, син дә килмәдең.*
*— Мин белмәдем бит.*
*3. — Безнең әни тӨш кҮргән. Мин, **имеш**, кияҮгә чыккан-мын...*
*— Мин дә бҮген тӨш кҮрдем. **Янәсе**, авылга кайткан-мын. Су буенда йӨрим икән. Нәрсә булыр икән?*
*— әбидән сорарга кирәк.*

**Задание**. Поставьте подходящие вводные слова, приведенные в конце задания.

1. Мин, ..., анда барачакмын.
2. ..., мин сезне күрмәдем.
3. ..., бүген яңгыр булмады.
4. Миңа, ..., ике билет бирегез, әле.
5. Кызлар дәрескә килмәделәр, ... .
6. ..., ул килергә тиеш.
7. Ул, ..., эшкә сәгать тугызга килә.
8. Мин сезне, ..., аңламыйм.
9. ..., бу проблема бик катлаулы.
10. Без, ..., бу турыда күп уйладык.
11. Минем, ..., бер гаебем дә юк.

Слова для выбора: *валлаһи, гомумән, мәсәлән, габу итегез, гадәттә, минемчә, күрәсең, әлбәттә, киресенчә, зинһар, ахрысы.*

Вот и все на сегодня. Сау булыгыз! Уңышлар телим!




# Урок пятьдесят первый

(Илле беренче дәрес)

— Исәнмесез!
— Хәерле кич!

Это наш с вами последний урок. Но я надеюсь, что уроки татарского языка у вас продолжатся. Вы будете уже понимать татарскую речь, будете внимательными к разговаривающим по-татарски, понимать отдельные слова и выражения по радио и телевидению, понимать речь актеров на татарской сцене, сможете вставить свое слово или предложение в разговоре, произнести к месту этикетные выражения, пословицы и поговорки...

Если вы внимательно изучали предыдущие уроки, вы усвоили особенности татарского языка.

Вы знаете уже, что татарский язык характеризуется особыми гласными и согласными.

Вы знаете, что в татарском языке, как и во всех тюркских языках, существует закон сингармонизма, по которому исконно татарские (тюркские) слова произносятся или только твердо, или только мягко. Закон этот играет большую роль в фонетике татарского языка.

Вы заметили, конечно, что ударение в татарском языке стремится к последнему слогу в слове, хотя есть отдельные случаи отхода от этого правила (ударение в вопросительных местоимениях падает на первый слог; на аффикс глагольного отрицания никогда не падает ударение, а падает на предшествующий ему слог; аффикс — частица вопроса **-мы/-ме** не принимает на себя ударения и ударение всегда предшествует этому слогу; частицы **бик, иң** (самый) — всегда ударные; в союзах, часто заимствованных из арабского и персидского языков, ударение падает на первый слог и т.д.). В речи словесное ударение объединяется с синтагматическим ударением и несколько уменьшается.

Вы также узнали, что в татарском языке существует всего 6 типов слогов, что говорит о стройности, упорядоченности звучания татарской речи.

Вам представляло большую трудность и то, что в в татарском языке (несмотря на то, что основным принципом орфографии является фонетический принцип написания, то есть пишется так, как произносится), разница между написанием и произношением довольно ощутима. Это объясняется несовершенством существующего татарского алфавита, созданного в конце 30-ых годов на основе кириллицы, и употреблением одних и тех же букв для выражения разных звуков. Этот алфавит не отражает истинного

звукового состава татарского языка, и общественное мнение склоняется в защиту алфавита на основе латиницы, возврат к чему, уже состоялся.

Вы узнали также, что в татарском языке нет категории рода, такой важной для русского языка; что в татарских словах корни не меняются, что к ним в определенной последовательности, не нарушая цельности корня, «прилепляются» аффиксы, обязательно твердые — к твердым словам, мягкие — к мягким словам; эти аффиксы имеют обычно только одно грамматическое значение. Исходя из этого татарский язык относится к агглютинативному типу языков.

Вы привыкли также к такой особенности татарского языка, как категория принадлежности, выражающей принадлежность предмета, лица кому или чему-нибудь, осуществляемой добавлением определенных аффиксов: где русский скажет **моя книга**, татарин скажет одним словом — *китаб-ым*.

Вы уже можете правильно добавлять аффиксы к именам в определенном порядке: сначала корень, к нему — аффиксы множественного числа, затем — принадлежности, затем — падежа. Например: *акча-лар-ыбыз-га* (нашим деньгам).

Вы, конечно же, заметили, что прилагательное и числительное в сочетании с именем не изменяются — изменяется только имя (*матур кызларга, матур кызларның, матур кызларны, матур кызлардан, матур кызларда; ике кыз, ике кызның, ике кызга, ике кыздан, ике кызда*).

Вам было трудно при изучении глагольных времен, ведь в татарском языке их в 3 раза больше, чем в русском. Только прошедших времен в татарском языке насчитывается 5. Временные формы различаются в зависимости от того, видел ли говорящий процесс сам или кто-то сообщил ему об этом, как давно этот процесс происходил и т.д.

Вы также заметили, что в татарском языке нет вида, что видовые значения русского языка передаются сочетанием основного глагола в неличной форме и вспомогательного глагола. Например: *укыдым — укып чыктым* (читал-прочитал), *әйттем — әйтеп бетердем* (сказал — высказал), *кычкырды — кычкырып Җибәрде* (кричал — закричал) и т.д.

В отличие от русского языка в татарском языке очень много неличных форм глагола, выступающих основными в сложных и составных глагольных формах: *сӨйли башлады* — стал говорить, *укып утыра* — сидит — читает, *әйтә тор* — пока говори, *ясый башла* — начинай делать и т.д.

Вы заметили, что в татарском языке согласование не играет большой роли; а согласование подлежащего и сказуемого в числе вовсе не обязательно, а в русском языке это очень важно. *Кошлар кайтты* — букв. птицы вернулась, что невозможно в русском языке.

Мы с вами узнали также и о том, что в татарском языке нет предлогов, есть только послелоги, которые стоят после знаменательных слов и выполняют те же функции, что и предлоги в русском языке. Помните?

*Мин әти белән МәскәҮгә барам.*

*Син мине вокзалга хәтле озат.*

*Син апаң кебек Җырлыйсың.*

Думаю, что перевода не потребуется.

Вы привыкли уже к постоянному порядку слов в предложении, по которому сказуемое всегда завершает предложение и ставится на последнем месте. Определение всегда предшествует определяемому слову — существительному, дополнение — глаголу, обстоятельства — глаголу-сказуемому.

Группа подлежащего предшествует группе сказуемого. В разговорной речи этот порядок может и нарушаться, как вы это заметили в диалогах. Например:

*а) — Кер безгә!*

*— Хәзер.*

*б) — Барыйк әле кинога!*

*— әйдәгез!*

Вы заметили, вероятно, обилие в татарской речи частиц, которые в большинстве случаев безударны и ставятся после самостоятельного слова. Они обеспечивают также мелодичность, певучесть и мягкость татарской речи, ее интонационное разнообразие.

Татарский язык отличается от русского и тем, что в нем имеются своеобразные типы придаточных предложений, в которых сказуемыми являются неличные формы глагола, которые не

согласуются с подлежащими. Таковы предложения: *Мин килгәндә, ул Өйдә юк иде.* (Когда я пришел, его не было дома). *әни килгәч, безгә бик рәхәт булды.* (Когда приехала мама, нам было очень приятно). *Мин китәсе автобус ярты сәгатькә соңга калды.* (Автобус, на котором я должна была уехать, опоздал на полчаса).

Вот, кажется, пока все, что касается особенностей татарского языка. Противопоставленность гласных звуков по твердости и мягкости, наличие строго определенных типов слогов, фиксированное место ударения на последнем слоге, существование всегда парных аффиксов в зависимости от твердости — мягкости корня или основы, глухости или звонкости последнего звука корня, устойчивый порядок слов в словосочетаниях и предложениях, предшествование придаточных предложений главному, строго определенная закономерность добавления всех видов аффиксов при сохранении неизменного корня позволяют говорить, как нам кажется, о стройности, упорядоченности, некоторой строгой формализованности татарского языка, что дало основание сказать исследователям, что по этим качествам татарский язык занимает одно из первых мест среди языков мира. А знание татарского языка, по данным ЮНЕСКО, дает возможность общаться и на многочисленных тюркских языках, а в этом смысле татарский язык входит в число 14 наиболее распространенных языков мира.

На прощание мы знакомим вас с замечательным стихотворением башкирского поэта Наджара Наджми, который подарил татарскому народу знаменитое стихотворение «Татар теле», отличающееся большой эмоциональной силой, публицистическим звучанием, напевностью, образностью, богатством языковых форм, за которое ему была присвоена государственная премия имени Г.Тукая. Возьмите словарь и попробуйте перевести это стихотворение.

**НаҖар НәҖМИ**

**Татар теле**

Вы, прадеды наши в недоле
мукою запрудивших лик,

на мельнице русской смололи
заезжий татарский язык.
(Ярослав Смеляков.)

Туган Җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган Җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йӨзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син кӨне-тӨне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт Җиле.
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере,
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
ДӨньяда кҮп нәрсә кҮрдең,
әй мӨкатдәс Тукай теле.

ТӨрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
ТӨрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас Үткәннәрең —
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

Многое в этом стихотворении вам понятно. Дадим несколько комментариев.

В словах *Җырдай, ир-егетләреңдәй, аксакалларыңдай* есть общий аффикс ***-дай (-дәй),*** который образует наречия и выражает значение **как, словно**: *как песня, как твои мужчины, как твои аксакалы.*

Переводы отдельных слов:

***моңлы*** **—** певучий, грустный, мелодичный
***Өзелеп тора*** **—** изгибается
***биле*** **—** талия (ее, их)
***шат чырайлы*** **—** приветливое лицо
***ачык йӨзле*** **—** с открытым лицом (радушием)
***дәртле*** **—** страстный
***гайрәтле*** **—** мощный
***фәннән*** **—** от науки
***гасырларның*** **—** веков
***афәт*** **—** нашествие
***олпат*** **—** величавый
***ассалар да*** **—** хотя и вешали
***киссәләр дә*** **—** хотя и рубили
***Үлмәдең*** **—** не умер
***чукынмадың*** **—** не крестился
***яндың*** **—** горел
***туңдың*** **—** мерз
***нишләтмәде*** **—** чего только не делала
***язмыш*** **—** судьба

***мӨкатдәс*** — священный, родной
***тӨрмә*** — тюрьма
***килмешәк*** — чужой, со стороны
***зиндан*** — неволя
***ярып*** — разорвав
***ялкынланып*** — пламенея
***тегермән*** — мельница
***тарта алмады*** — не сумела перемолоть
***кабатланмас*** — не повторится
***Үткәннәрең*** — твое прошлое
***кабатлар*** — повторит
***гасырлар*** — века
***дуслык*** — дружба.

В этом стихотворени вы заметили и обратный порядок слов, диктуемый рифмой и ритмом стиха. Каждая строфа завершается обращением к татарскому языку.

* * *

*Кадерле дуслар! Татар теле дәресләре тәмамланды. Сезгә зур уңышлар, шатлыклы кӨннәр, исәнлек-саулык, ак бәхетләр теләп калам. Кем дәресләр белән танышып барды, аларга зур ихтирамымны белдерәм. Рәхмәт сезгә!*

*Укытучыгыз — □азан дәүләт университетыны татар теленә өйрәтү каб̂едрасыны мөдире профессор Флера ханым Сафиуллина.*

# Ӡекстлар

**Гомәр Бәширов**

(Татарстанның халык язучысы, Тукай бҮләге лауреаты, ДәҮләт премияләре лауреаты).

**Менә тамаша**

Укытучы дәрестә балаларга яңа тема аңлаткан.

— Барыгыз да аңладыгызмы? — дигән.

— Юк, аңламадык! — дигәннәр укучылар.

Икенче мәртәбә аңлатып чыккан да, тагын сораган:

— Инде аңладыгызмы?

Балалар тагын хор белән:

— Юк, аңламадык, — дип Җавап биргәннәр.

Укытучы Өченче мәртәбә аңлаткан да:

— Инде аңлагансыздыр бит? — дигән.

— Юк, бу юлы да аңламадык әле! — дигәннәр.

Укытучы моңа бик аптырап, башын кашырга тотынган.

— Мин инде хәтта Үзем дә аңладым. ә сезгә Һаман да барып Җитми икән әле, — дигән.

**Фамилияне корбан итеп...**

Мәгариф бҮлегенең инспекторы белән мәктәп директоры урамнан баралар икән. Койма буена утырткан канәфер чәчәген ботарлап маташучы бер малайга кҮзләре тӨшкән.

— Менә тәрбия нәтиҖәсе! — дигән инспектор.

Директор, кызарынып, малайга:

— Халитов, нишләвең бу?! — дип кычкырган.

— әти, безнең фамилия Хамитов бит, оныттыңмыни? — дигән малай.

**Булышкан**

Атасы эштән кайткач, малаеннан хәл-әхвәл сораша башлаган:

— Я, бҮген ни эшләр бетердең? Уйнарга чыктыңмы? — дигән.

— Юк, беркая да бармадым.

— Ни генә эшләдең соң?

— Мин энигә минем Өйгә бирелгән мәсьәләләрне чишәргә булыштым.

**Телевизор шаукымы**

— Балалар, — ди укытучы. — БҮген кич ай тотылачак. Бу — табигатьтә бик сирәк була торган бик кызык кҮренеш. Ай нәкъ 21 сәгать 45 минутта тотыла. Карарга онытмагыз.

Соңгы партада утырган бер малай:

— Апа, кайсы программада тотыла ул? — дип сорый.

**Тереклек иясе**

Укытучы:

— Җирдә дә, суда да яшәҮче Җан ияләрен ничек дип атыйлар?

Укучы:

— Матрос, дип...

**Менә сиңа...**

— ГҮзәл, нигә бҮген мәктәпкә бармадың? — дип сорый кҮрше апа беренче класста укучы кыздан.

— Минем температурам бик зур...

— КҮпме?

— Кырык.

— Кырык?! — дип гаҖәпләнде кҮрше апа.

— әйе, әнием утыз Җиде дә Өч, диде. Кушкач, кырык була ич...

**Физика дәресендә...**

Укучы сӨйли:
— Архимед судан чыга да «Эврика!» дип кычкыра.
— Бу нәрсәне аңлата инде? — ди укытучы.
— «Эврика» «таптым» дигәнне аңлата.
— Архимед нәрсә тапкан була инде?
— Нәрсә, дип... Сабындыр инде.

**Яңа шәһәр**

— Йолдыз, син нинди шәһәрләр беләсең?
— МәскәҮ, Казан, Петербург, Командировка...
— Командировка дигән шәһәр дә бармыни?
— әйе, минем әти гел шунда бара.

**И замана, замана...**

География дәресендә бер укучы Кавказ тауларын Һиндикуш белән бутаган, картада Африка чҮлләрен Боз диңгезеннән эзли икән.

— Ярый алайса, Үз якларыбызга кайтык. Волга белән Жигули кайда?

— «Волга» кҮрше абый гаражында, ә «Жигули» безнекендә...

**Башында... Җилләр**

Математика дәресендә укытучы:
— Гәрәй, унбергә унберне кушкач, ничә була? — дип сорый.
— Ике футбол командасы килеп чыга, — ди малай.

**Үзенчә**

— Укучылар, тәҮлектә ничә сәгать вакыт бар? — дип сорый укытучы.

— Егерме ике, — дип Җавап бирә укучы.

— Ничек алай?

— КҮптән тҮгел генә Үзегез кӨннәр ике сәгатькә кыскара, — дип әйттегез ич...

## Йота бит!

Мәликә анасы белән «Диңгез тӨбендә» дигән мультфильм карыйлар икән. Кинәт кызый анасына кычкырган:

— әни! СҮндер тизрәк телевизорны!

— Ни булды, кызым? — дигән анасы.

— КҮрмисеңмени? әнә акула алтын балыкны куып килә, йота бит инде, йота!

## Телефонда

— Алло! Арпаязмы бу?

— әйе, Арпаяз. ә син кем?

— Мин интернаттан.

— әҺә! Аңлашыла. Арпаязда сиңа кем кирәк?

— әнинең хәлен беләсем килгән иде...

— ә, алаймы? әниең исән-сау, матур гына яшәп ята. Бая бәрәңге ала иде...

— әнине телефонга чакырмассыңмы икән, абый, ә?

— Була ул! Синең анаң ни исемле әле?...

## Уннан биш...

КӨтҮче Үзенең улына кӨтҮдәге атларны санап килергә кушкан. Улы санап килгән дә әйткән:

— Егерме бӨтен, уннан биш! — дигән

— «Уннан биш» дигәнең нәрсә?

— Тай!.. — дигән улы.

## Менә гаҖәп!

— әни, син кайда тугансың?

— Мин Казанда туганмын, улым!

— әти кайда туган?

— Ул МәскәҮдә туган.

— ә мин кайда тудым?

— Син авылда тудың.

— Менә бит ничек! Өчебез Өч Җирдә туганбыз, шулай да бер-беребезне тапканбыз.

### Эшлекле сорау

— Бабай, син кайчан бабай булдың?

— Син тугач, улым.

— Алайса, моның Өчен син миңа нәрсә бирәсең?

### ШҮрәле кайда яши?

— Бабай! Синең ШҮрәлене кҮргәнең бармы?

— Бар.

— Кайда?

— Тукай китабында.

— ә ул кайда кҮргән?

— Ул әкияттә кҮргән...

### Курчак әнисе

— Кызым, курчагыңны кҮрмим. Кая куйдың?

— Мин аны йокы бҮлмәсенә кертеп яткырдым. Хәзер телевизордан балаларга ярамый торган фильм кҮрсәтәчәкләр.

— ә сиңа ярыймыни?

— Мин курчакның әнисе бит. әниләр белән әтиләргә карарга ярый аны...

### Ул да укый

Бер егет кӨн саен китапханәдән бер китап ала да икенче кӨнне Үк тапшыра икән. Китап бирҮче кыз беркӨнне аңа алгебра дәреслеген биреп Җибәргән. Егет икенче кӨнне Үк аны тапшырырга килгән. Кыз сорашкан:

— Кызык китапмы? Нәрсә турында?

Егет бик белгәндәй сӨйләп киткән:

— әй, әллә нәрсәсе юк ла. Алгебра исемле бер кыз булган, шуның маҖаралары турында икән.

## Тапкыр Җавап

Бер студенттан:

— Ник син Һәрвакыт театрда галеркада утырасың? — дип сорыйлар икән.

— Кинода беренче рәттә утырып туйдым, — дип Җавап биргән студент.

## Җамалый кодаларда

Бер кеше Үзенең танышын кунакка чакырган.

— Сез кайда торасыз соң? — дип сораган теге кеше.

— Без Җамалый кодалар янында торабыз, — дигән чакыручы.

— ә Җамалый кайда тора?

— Ул безнең янда тора, — дигән теге кеше.

## Җор кеше

Үләр вакыты Җиткәч, бер Җор кеше иң якын дустын чакырып китергән дә, аңа сәгатен бҮләк иткән.

— Минем тӨсем итеп тотарсың. Мин мәңгелек йортка китәм, анда вакытны белҮ Һич зарур тҮгел, — дип шаярткан.

## Авыл саен йорт сал

әти кеше, малаена васыять итеп, авыл саен йорт салырга кушкан.

— Ул кадәр байлыкны кайдан алыйм, әти? — дигән малае.

— Аның Өчен байлык кирәкми, Һәр авылда танышларың, дусларың булсын, — дигән атасы.

## Суны каян ала?

Су тегермәнле авылда яшәҮче ике агай, ерак сәфәргә чыккач, Җил тегермәне яныннан Үтәләр икән.

— әй дим, бу тегермән ничек эшли икән? — дип сораган берсе.

— Ник, Җил тегермəне бит ул.
— Җил тегермəне икəнен Үзем дə белəм, суны кая ала икəн?

**Саранның Җавабы**

Саран кеше кунакка баргач, чəй салучы əби моннан сорый икəн:
— Чəйне куе эчəсеңме, сыекмы? — дип.
Саран дӨресен əйткəн:
— Үзебездə сыек эчкəгəндер, кешедə куесын эчəсе килə, — дигəн.

(Мəзəклəр тҮбəндəге китаптан алынды: Туган тел мəзəклəре. Җыючы Һəм əдəби эшкəртҮче Г.Бəширов. — Казан: Тат.кит.нəшр., 1995.)

* * *

Ш.Галиев.

# Хикмəтле сҮзлəр

•Акыллы кеше картайгач та матур кала.

•Үткəн кӨннəрнең тӨннəре дə якты.

•Карт йӨрəккə шатлык та авыр.

•Яшьлəргə — романтизм,
Картларга — ревматизм.

•Яшьлекнең грамматик ялгышлары картлыкта драматик язмышка əйлəнə...

•Авыру башта йога,

Аннары — ега.

* * * * * *

•Мактауны халык алдында әйтсеннәр,
Тәнкыйтьне — колагыма...

•Ашауны урынбасарга тапшырмыйлар.

•ТҮрәнең тӨшкәнен генә сҮгәләр.

•Яратабыз да инде Үзебезне яратканнарны!

* * * * * *

•Эчкән кеше башы белән йӨри, аяклары белән уйлый.

•Җиде кат Үлчә, бер кат та ... эчмә!

•Буш вакыттан буш шешәләр генә калган...

•Башта ава шешәләр, аннан ава кешеләр.

* * * * * *

•Гайбәтне бушлай бирәләр, әмма кыйммәткә тӨшә...

•Бердәнбер яхшы ягы шул: начарлыгын яшерми.

* * * * * *

•Язның беренче карлыгачлары — кара каргалар килде.

•Язын бар йӨрәкләр дә бер яшьтә.

* * * * * *

•Сәгать әкрен йӨри, вакыт тиз уза.

•Мәңгелек утны да мизгел кабыза.

•Сәгатең алга китсә, Үзең артка калырсың.

•Иң тиз туйдыра торган эш — ял...

* * * * * *

•Яратмаган кеше белән яраткан эшне дә эшләп булмый...

•Ашауда ялкаулар юк.

•Ел авыр булса да, юлчылар бетми.

•Чор нинди — Җыр шундый!

•Беренче булырга кҮнекте исә, кеше икенче урынга кала.

•Суын алмаган кое тизрәк корый.

* * * * * *

•Акбур белән кара фикер дә язып була.

•Югары белемне кҮпләр ала, тирән белемне кемнәр ала?

•Акыл теше ахмакка да чыга.

•Башы тулы цифр: гел нольләр дә нольләр.

* * * * * *

•Баласызлар бакчага чәчәк утырта, балалылар бәрәңге утыра.

•әти-әнине дә аңлый башладык, Үзләре генә юк.

•Оныклар бабайны яшәртә.

•Бала чагың — баллы чагың.

* * * * * *

•Мода — хатын-кыз дигән кибетнең витринасы...

•Кошелегыңны югалтсаң да, кешелегеңне югалтма.

# Татар поэзиясеннән Үрнәкләр.

*Г.Тукай.*

**Безнең гаилә**

әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай Һәм бер песи.
Безнең Өйдә без ҖидәҮ: безнең песи — Җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнең лә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: Өйне тычкан явыздан саклый ул.

Дәрдемәнд

* * *

Кил, Өйрән, и туган, бер башка телне,
БҮтән телләр белҮ яхшы ҺӨнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

* * *

Стремись, мой друг, постичь язык чужой,
Ведь он для нас — живое ремесло.
Но языки не путай, милый мой! —
Свои познанья обратишь во зло.
(Перевод В.Ганиева)

*ЗӨлфәт*

**Туган тел хакында**

Тел ачылгач әйтә алсаң: «әни!» — дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: «әти!» — дип —
КҮзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң: «әни!» — дип,
Соң минутта әйтә алсаң: «әти!» — дип —

КҮзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

*Г.Афзал*

* * *

әшәке кешеләр була.
әшәке халык булмый.
әшәке тарихчы була!
әшәке тарих булмый.

*Н.НәҖми*

* * *

Кичә дустым мине әрләде,
ә дошманым бҮген мактады.
Дустымның шул әрләҮ сҮзләре
Дошман мактавыннан саклады.

*Н.НәҖми*

Акыл

Акыллыдан акыл артмас —
Акыллы Һич акыл сатмас.

*Н.НәҖми*

* * *

Гомернең бар ике очы:
Кеше туа, Үлә.
Үлгәч, кешене Җирләргә
КҮпме кеше килә!
А кайберен озата бит
БӨтен дӨнья йӨзе.
ә тапканда, әни таба аны
Тик бер Үзе.

*И.Юзиев*

**Сәйдәш урамында уйлану**

Исән чакта сине кҮрәлмәдем,
Баралмадым синең янына.
Ләкин кҮңел,
КӨннәр Үткән саен,
Якын дустай сине сагына.
ГӨлләр,
Назлы гӨлләр,
Язны сагынып чәчәк аталар,
Урам.
Шушы урам, истәлегең булып,
Синең исмең белән аталган.
Яңа Җырларыңны кӨйли-кӨйли,
Бу урамнан кҮпме Үттең син?..
Салих абый,
Урамнарда гына тҮгел
КҮңелләрдә
КҮпме моң калдырып киттең син.
Менә берәҮ
Җилләр исҮенә
Тәрәзәсен ачып куйган да
Өзелеп-Өзелеп синең кӨйне уйный
Чумган килеш тирән уйларга.
Юк,
Бер без генә тҮгел,
Хәтта
КӨйләрең дә
Сагына сине — язлар Җырчысын.
Салих абый,
Кабатланмас бер матурлык булып,
Син тормышны бизәп торырсың.
Менә урам.
Сәйдәш кҮңеледәй
Киң Һәм матур...
әйтерсең лә
Моңнарыннан аның нурланган.
Менә Сәйдәш.
Илебезнең мә»рур данын Җырлап
Марш булып Үтә урамнан.

Ул моң булып яши кҮңелләрдә,
Ул рух алып керә Өйләргә.
Их,
Исән чакта сине кҮрәлмәдем
СҮзем бик кҮп иде сӨйләргә.

Р.Фәйзуллин

**Пушкин кабере янында**

Колакта —
«Вечерний звон».
Уемда —
«кичке азан».
КҮңел тӨпкелендә —
моң.

Р.Фәйзуллин

Чегәннәр

Юл читендә чатырлары.
Башкалада — театрлары!
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сәнгате чыкмаса юкка,
Үлем юк халыкка

Р.Фәйзуллин

**Кичке тӨсләр**

Ак пароход.
Кара дулкын.
Кызыл маяк.
Соры ком.
Зәңгәр кҮктә
Якты йолдыз.
Яшел ярда
Сары кыз.

Р.Фәйзуллин

**Картлар сҮзе**

Ике хәзинә бар дӨньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гӨлдә булсын!
Китапханә — икенчесе. КҮңелдә булсын!
Базар болай да калыр...

*Р.Фәйзуллин*

**ТӨнге Алупка**

Диңгез — кӨзге.
Ай — бер шәм.
Ай-Петридә —
Чишмәм!
Чылтырый да
Чылтырый.

*М.ә»ләмов*

* * *

Карт:
— Буйга да Үскәнсең, улым,
Ходайдан бәхет сора!
Егет:
— Бәхетме, бабай?
Ул бары
Ике Өй аша тора!

*Р.Гатауллин*

* * *

Янган йӨрәк, сузылган кул —
минеке.
Ике толым, кап-кара кҮз —
синеке.
Егерме ике кояш эзе —
минеке.
Уналты яз, гӨлчәчәкләр —
синеке.
— — — — — — — — — — —

... Ал йӨрәгем! БҮгеннән ул
синеке.
Синең йӨрәк булсын ләкин
минеке.
Ал кулларым! Нык каты кул —
синеке.
Язың-ямең булсын ләкин
минеке.
Син ризамы? «Юк!» — дисеңме?..
Синең эш.
«СӨймә мине, оныт!» — дисең?
Синең эш!
... Тик оныту Һәм онытмау
Минем эш.

*М.Галиев*

**Кайту**

(этиләр Җыры)

Олы юлдан яуга киткән чакта
таң жиленнән томан таралды.
Авыл башындагы куш наратка
атлар да бит борылып карады.
Һаваларда торна тавышлары,
ишетелә канат кагышлары,
кошларда да кеше язмышлары,
чит Җирләргә китеп барышлары.

Туган якның хәбәрләрен белдек
ызаннардан искән Җилләрдән.
КҮпләребез олы юлдан кире
кайталмады ерак илләрдән.
Һаваларда торна тавышлары,
ишетелә канат кагышлары,
кошларда да кеше язмышлары,
чит Җирләрдән кайтып барышлары.

З.Мансуров

**«Хәзергә...»**

«Хәзергә...» — дип кул бирәбез
Кич кҮрешер ярга да.
Җир читенә олагабыз,
биштәр асып аркага:
«Хәзергә...»

«Хәзергә...» — дип кулын изи
ЙӨз яшәгән картлар да.
БҮтән мәңге кҮрешалмас
Дуслар кала чатларда:
«Хәзергә...»

«Хәзергә...» — дип саубуллашып,
кҮмеләбез елларга.
Җирдә кабат кҮрешмәсәк,
очрашырбыз Җырларда...
— Хә-зер-гә!..

*М.ә»ләмов*

* * *

Кич. Кече Тирән кҮл.
Су коенам.
Тып-тыныч.
Өстә йолдыз, аста йолдыз.
Батар идем, эчтә йолдыз,
Ул да батса... куркыныч.

*М.ә»ләмов*

**Ай яктыра, йолдызлар яна...**

Сагышлы тӨн. Өстә — зәңгәр кҮктә
Ай яктыра, йолдызлар яна...
Һәм китәсе килә чиксезлеккә —
Иң ахыргы йолдызларга таба...

Сагышлы тӨн. Зәңгәр кҮктә — тӨптә

Ай яктыра, йолдызлар яна...
Сикерәсе килә мәңгелеккә,
Иң ахыргы йолдызга таба.

*М.Галиев*

**Дулкынга карап**

Килә дә китә дулкыннар,
килә дә китә генә.
Кагыла Җиле диңгезнең
синең ак итәгеңә.

Килә дә китә дулкыннар,
килә дә китә генә.
Мин дә бит бҮтәнчә идем,
бҮтәнчә кичә генә.

Килә дә китә дулкыннар,
килә дә китә генә.
Тизләтә йӨрәк тибешен
киләчәк исәбенә.

Килә дә китә дулкыннар,
килә дә китә генә.
әзер бул синнән алдарак
тормыштан китәремә.

# Җөрле стильләрдән текст үрнәкләре

ЯЗМАЧЫЛЫК һәМ Мә»РИФәТ

Чыганаклар һәм фәнни эзләнҮләр борынгы тӨркиләрнең бик борынгы заманнардан бирле дәҮләт мәдәниятенә һәм шуңа бәйләнешле язма культурага ия булганнары хакында сӨйли. Соңгы елларда бу хакта сенцациягә якын ачышлар булып тора. Үз вакытында казакъ шагыйре Олжас СӨләймановның «Аз и Я» исемле китабы шау-шу кузгаткан иде. Ул Үзенең бу китабында тӨрки язма мәдәниятенең, хәтта шумер һ.б.борынгы культураларда да урын алуы хакында язды.

Соңгы елларда академик М.З.Зәкиев безнең Җирләрдә Болгар дәҮләтенә кадәр Үк югары мәдәнияткә ия булган тӨрки Биарм дигән дәҮләт хакында Үзенең фикерләрен язып чыкты.

Идел-Урал буйларында таралган һәм V—VII гасырларга караган акчалар һәм алтын, кӨмеш савыт-сабалардагы язулары озак вакытлар бик кҮп галимнәрнең и»тибарында булды ә.Г.МӨхәммәдиев бу язуларның борынгы, моңа кадәр легендар дип исәпләгән тӨрки цивилизация — тӨркичә һәм фарсыча Туран, кытайча Кангюй дип аталган дәҮләткә караганлыклары турында язды. Илнең Үзәге Урта Азиянең Өргәнеч шәһәре янында булган. ТӨньяктагы Кама, Урал буйлары да дәҮләтнең чик биләмәләрен тәшкил иткән. ә.Г.МӨхәммәдиев шундый тӨрки кабиләләр дип археологиядә «Имәнкискә культурасы» кабиләләрен (III гасыр ахыры — VIII йӨз башы) таный. Галим тәңкә, савыт-сабалардагы туран язулары тӨрки рун язуларына кадәр мең елдан артык элек барлыкка килгән дигән фикердә тора. Туран язулары тӨркиләргә мең еллап хезмәт иткәннәр. Алар б.э.к. барлыкка килгән арами әлифбасына якын. Арами язуы Үзе финикия язуыннан килеп чыккан. ә араминың Үзеннән соңрак сурия, гарәп, пәһләви, уйгыр, монгол язулары туган.

Болгарларга кадәр безнең якларда таралган борынгы тӨрки эзләр хакында тагын шуны әйтәсе килә. Еш кына галимнәр арасында Азов болгарларының ни Өчен нәкъ безнең якларга килҮләре хакында сҮз булып ала. Бу тӨбәкләрдә болгарларга кадәр Үк тӨрки мәдәният таралган һәм тӨрки кабиләләр

яшәгән икән, болгарларның безнең якларга килеп тӨпләнҮләре дә табигый.

Язучы, галим Нурихан Фәттахның Фест дисбесенә багышланган китабы зур кызыксыну белән укыла. СҮз XX гасыр башында ук Крит утравының Фест шәһәре янындагы борынгы сарай хәрабәләрен казыганда табылган балчыктан әвәләп эшләнгән дисктагы рәсем-язулар турында бара. Н.Фәттах моннан 3700 еллар элек тӨшерелгән рәсем-язуны тӨркичә укырга омтыла. Шаман кулында бу диск әйләнгәндә, (тәсбих тарткан кебек) спираль буенча укып, (карамыйча бармаклар белән капшап та була)һәр сҮзне әйтеп барган. Н.Фәттах фикеренчә, бу язу-дисбе борынгы Грециягә кадәр кҮп элек яшәгән һәм югары ҮсешкӘ ирешкән Крит цивилизациясенә карый. Бу китапта борынгы Шумер, Мисыр һ.б. цивилизацияләрдә дә тӨрки катлам булуы хакында языла.

Н.Фәттах фаразына аваздаш ачыш шулай ук соңгы елларда булды. Бу хакта чит ил һәм алардан кҮчерелеп Татарстан газеталарында да мәкаләләр чыкты. 1924 елда Франициянең Виши Өлкәсеннән бик кҮп кисәкләрдән торган язулы балчык тактачыклар табыла. Галимнәр аларның 4500 ел элек язылганын исбатлыйлар. Бу язулар бҮгенге кӨндә Франциянең Глозель музеенда сакланганга кҮрә, аларны Глозель язулары дип йӨртәләр. Соңгы елларда бу язуларның кҮчермәләре тӨрек галиме Кязым Миршан кулына килеп эләгә. Галим аларны, бер яктан, борынгы тӨрки руннарына, икенче яктан, этруск язуларына охшатып таң кала. ТӨрек галиме фикеренчә, тӨрки язуы булган Глозель әлифбасы нигезендә этруск, финикия, хәтта грек язулары да барлыкка килгән. Бу хакта Сорбонна университетында махсус Җыелган конференциядә дә тыңлыйлар. Анда бик борынгы заманнарда Урта Азиядән Атлантик океанга кадәр югары ҮскӘн тӨрки цивилизация булган дигән фикер әйтелә.

Элекке тӨрки дӨньясы турындагы аксиома хәленә Җиткерелгән карашларның шиккә алынуы дәвам итә. Алда китерелгән ачышлар, фикерләр чыннан да фаразлар гына булып калырмы, әллә аларны ныгытырлык башка ачышлар да булырмы — моны вакыт кҮрсәтер.

*(Гамирҗан Дәүләтшин)*

* * *

Хикмәт тә шунда шул. Җиргән гадәти генә тҮгел, гаҖәп кызыклы авыл булган икән ул. Вакытында мин шундый авылда яшәҮнең кадерен белмәгәнмен, аның кызыклы кешеләрен, катлаулы тарихын ӨйрәнҮгә әһәмият бирмәгәнмен. Шулай да аның Үзенчәлекләре турында миңа бу китабымда кайта-кайта сӨйләргә туры килер әле. Хәзергә артык Җәелмичә, шуларын гына әйтим: ул бик зур авыл. Анда дҮрт тӨрле халык яши: руслар, татарлар, чувашлар, мордвалар (без аларны мукшылар дип йӨртәбез). Татарлар Үзләренә, чувашлар Үзләренә аерым урам-урам булып яшиләр. ә руслар белән мукшылар — аралаш. Якынрак белеш, яки Җиргәнчә әйтсәк, знакум булмаса, без аларның кайсы мукшы, кайсы рус икәнен аермыйбыз да. ЧӨнки мукшылар кҮбесенчә Үзара да русча сӨйләшәләр. Бары да диярлек татарчаны да белә. Тик аны бик Үзләренчә итеп, Үзгәртеп сӨйлиләр: «Кая киттең?» дип сорыйсы урында «Кая киткән?» диләр, «Кая бардың?» урынына «Кая барган?» Татарлар да тӨзәтеп тормый, аларга яраклашып, «Урманга киткән», «Базарга барган» дип Җавап кайтаралар. Сорау бирергә туры килсә дә, аңарга Җиңелрәк аңлашылсын Өчен, Үзләренчәләштереп сорыйлар: «Нихәл, КуҖма дәдәй, синеке картаймаган? Авырмаган?» (Янәсе: нихәл, КуҖма агай, бик картаймыйсыңмы әле, чирләмисеңме?) Һәм Үзара бик яхшы аңлашалар.

Чувашлар турында әйтәсе дә тҮгел: Һәр чуваш Үз теле Өстенә чатылдатып русча да сӨйли, татарчаны да Үз ана теле дәрәҖәсендә диярлек белә. Хәтта Үзара сӨйләшкәндә дә, татарча гына сӨйләшеп йӨрҮчеләре бар...

*(Мирсәй әмир)*

* * *

«ДӨньяда... бер генә хезмәтнең дә, ихтимал, шундый хӨр, тарихның Үзе кебек чал, милли дә, интернациональ да Үз бәйрәме юктыр. ә игенчелекнең шундый бәйрәме бар. Ул бәйрәмнең туган Җире — Идел буе болгарлары яшәгән тӨбәк. Ул бәйрәмнең исеме — Сабантуй. Элек ул язгы кыр эшләрен

башлау бәйрәме булган. Хәзер исә Сабантуй — язгы эшләрне тӨгәлләҮ бәйрәме...

Кайчандыр, борынгы заманнарда, Сабантуй бәйрәмен игенчеләр генә уздырган. Хәзер исә Татарстан индустриаль республикага, борынгы Һәм яңа шәҺәрләр, иген Һәм нефть, машина тӨзелеше Һәм фән йортлары, зур культура Һәм сәнгать республикасына әйләнде. әнә шуңа кҮрә дә аның Сабантуе да, игенченеке генә булудан узып, нефтьче, машина тӨзҮче, фән-сәнгать кешесе, очучы, тимер юлчы, химикның уртак бәйрәменә әверелде...

Арыш баш кысып, серкә очырырга Җыенган кӨннәрдә була ул Сабантуй... Сабантуй атнасы кҮңелләрне Җилкендерә. Ул атнада тагын да тырышыбрак эшлисең, ул атнада искиткеч кҮңел кҮтәренкелеге, хезмәт омтылышы... ЧӨнки ул — хезмәт алдынгылары, булганнар, уңганнар бәйрәме (...)

...Ул бәйрәмдә борынгыдан килгән бик кҮп кҮркәм гадәтләрне әле дә саклыйлар. Арадан берсе — бу бәйрәмнең Идел буенда яшәгән барлык милләтләрнең дә уртак, интернациональ бәйрәме булуы. Моның тамыры тирәнгә, тарихка барып тоташа. Татарларның дини бәйрәмнәрен рус агай белмәгән. Белсә дә, ул аның мә»нәсен аңламаган. Ләкин татарның бер бәйрәмен рус яхшы белгән. Ул — Сабантуй.

Сабантуй — әдәплеләр бәйрәме. Борынгы заманнардан килгән традиция буенча, мәйдан уртасына исерек кешене бӨтенләй кертмиләр. КӨрәшкә керҮ турында уйлыйсы да юк. Мәйдан уртасына кызмача баштан килеп керҮ ул — халыкны, тәртип саклаучы аксакалларны ихтирам итмәҮ дигән сҮз. Халык мондый кешене гафу итми, исерек кҮренсә, таза егетләр аны тиз генә мәйдан уртасыннан алып чыгып китәләр. Элек-электән шулай килгән...

Татар авылларында хезмәт сӨймәгән, эш эшләмәгән кешегә, борынгы заманнардан килгән гадәт буенча, урын булмаган...

Ләкин авылда бер-ике кеше Сабантуй алдыннан 10-15 кӨн кыр эшләренә йӨрмәгән. Моңа халык Үзе юл куйган, Үзе шулай кушкан. Ул кешегә мондый вакытта зур бер сарык суеп ашатканнар, алдында теләгәнчә йомырка, бал-май торган. Теге кеше ял иткән, ашаган, кӨч Җыйган. Ул — кӨрәшче. Сабантуйда аңа шушы авылның данын яклап кӨрәшергә кирәк булачак. Карт-

Картларның бӨтен Өмете шунда... КӨрәшченең татар халкы арасында абруе искиткеч. Хәзер дә шулай: Сабантуйда, гадәттә, колхозның иң тырыш механизаторлары, терлекчесе, шоферы кӨрәшә, арадан берсе батыр кала. Эшлексезләрне, колхоздан колхозга кҮчеп, «озын акча» эзләп читтә йӨргәннәрне колхоз Сабантуенда яратмыйлар...

КӨрәшне кҮзәтеп торучылар — авылның иң могтәбәр картлары...

ТҮгәрәк эчендә, озын таяклар тотып, тәртип саклап йӨрҮче картларны Сабантуйда әле дә кҮрергә мӨмкин...

Моннан биш йӨз ел элек, Җиде йӨз ел элек ничек капчык сугышсалар, әле дә шулай. Борынгы заманнарда ук ничек кашыкка тавык йомыркасы куеп, кашык кабып йӨгерешсәләр — әле дә шулай. Матур гадәтләр шулай саклана алар. Сабантуй йоласы, аның Җырлары гасырлар буе халык кҮңелендә, телендә яшәгән, шомарган. Ул йолалар халыкның Үзе кебек Үк кӨчле, яшәҮчән булган. әнә шуңа кҮрә дә алар безнең кӨннәргә кадәр килеп Җиткәннәр.

...Сабантуй атнасы тәмам. Бәйрәмгә кайткан кунаклар да инде китә башлыйлар. Сабантуй рухы кунаклар белән шәһәргә кҮчә...

Авыл Җәйге кыр эшләренә әзерләнә. ә Сабантуй булган мәйданның бер кырыенда, әле генә Үткән хезмәт бәйрәменең матур истәлеге булып, зәңгәр кҮккә ашкан ак колга Җәйге Җилдә чайкалып утыра — Җиңелчә сызгырып тыныч хезмәткә мәдхия Җырлый. Ул колга шулай Җәй буе кояшта ялтырап утырыр, иген басуындагы комбайн штурвалындагы егет тә, иртән фермага баручы кыз да аңар карап хезмәт бәйрәмен искә алыр, матур хисләр һәркайсын хезмәткә рухландырыр. Җилгә чайкалып утырган ул колгага вакыт-вакыт авылның ак сакаллы карты да кҮз салыр: ул колга аның типсә тимер Өзәрдәй таза вакытын, кызыл башлы сӨлгеләрне бӨтереп бил алышкан чакларын хәтерләтер...

әнә шулай кадерле, бик кадерле йола ул Сабантуй дигән халык бәйрәме!

*(Мљхђммђт Мәһдиев)*

* * *

Чәй Өстәленә чәчәкле ашъяулык Җәелә. Өстәл уртасына буйдан-буйга варенье, бал, шикәр, конфет салынган вазалар тезеп чыгыла. Аларның ике ягына роза, кош теле, бавырсак, пәхләвә, чәкчәк, талкыш кәләвә кебек камыр ашамлыклары куялар. Һәр кунак алдына десерт тәлинкәсе белән тӨрле камыр азыгы — паштет, мҮк Җиләге бәлеше, эремчек бәлеше Һәм башкаларны куярга кирәк. Тәлинкәдә Өч тӨрле ризык булырга тиеш.

Өстәлнең берничә Җиренә сай тәлинкәгә юка гына итеп телемләп лимон куярга кирәк. Кунаклар Өстәл янына утырып беткәч, чәй китерәләр. Һәр чынаяк тәлинкәсенә балкашык куела. Кунаклар розеткаларына варенье салып ала алсын Өчен, Һәр варенье вазасында да балкашык булырга тиеш. Кунаклар кҮп булмаса, самоварны Өстәлгә куярга мӨмкин. Ул табынны бизәп торачак, чәй дә тәмлерәк тоелачак.

Чәй эчкәннән соң, Өстәлне Җыештырырга, махсус щетка белән тәлинкәгә ризык валчыкларын себереп алырга да, вазалар белән Җиләк-Җимеш — алма, груша, виноград, әфлисун Һәм башкаларны чыгарырга кирәк.

*(Ю.әхмәтҖанов. Татар халык ашлары)*

## *Таблица гласных звуков*

| Гласные | Написание | Примеры |
|---|---|---|
| мягкие (переднего ряда) | ә, Θ, Y, е (э), и | әни, әнә; Θлеш, Θй, кΘз, кΘймә; Yзем, сYз, кYрY, бел, эт, керпе, элгеч; ил, имән, тимер, икмәк |
| твердые (заднего ряда) | а, о, у, ы | ат, ата, бар; олы, тоз; урам, кул, тору; ылыс, кыр, туры |

## *Закон сингармонизма*

| Виды сингармонизма | Примеры | |
|---|---|---|
| гармония по ряду<br>а-ә, у-Y, о-Θ, ы-е (э) | ба-ра-лар-мы?<br>бә-рә-ләр-ме?<br>у-ра-лар-мы?<br>Y-рә-ләр-ме? | то-ра-лар-мы?<br>тΘ-рә-ләр-ме?<br>ы-ша-ныч-лы-мы?<br>эш-лек-ле-ме? |
| губная гармония<br>о → ы → о<br>Θ → е → Θ | солы [соло]<br>коры [късоро]<br>болын [болон] | сΘлге [сΘлгΘ]<br>кΘзге [кΘзгΘ]<br>тΘтен [тΘтΘн] |

## *Типы слогов*

| Типы | Примеры |
|---|---|
| гласный | а-па, ә-ни, у-рам, Y-лән, о-лы, ы-лыс, и-дән, Θ-леш |
| гласный+согласный | ал-да, эн-кәй, ур-та, Yс-те, он, Θн, ит |
| согласный+гласный | та-ра, тә-рә-зә, ку-рай, кY-лә-гә, то-ра, тΘ-рә, ни-чә, ни-гә, ти-рә, те-ре, сөй-лә |
| согласный+гласный+согласный | бар-ды, бәр-де, куй-ган, кYр-де, |

| | |
|---|---|
| | тор-ды, тӨр-де, кил-де, бел-де, кӨл-де, тот-ты |
| гласный+согласный+согласный (р, т, й, н, л) | ант, әйт, илт, урт, алт-мыш |
| соглас-ный+гласный+согласный+согласный (р, т, й, л) | кайт, кӨрт, керт, тӨрт, дерт, дҮрт, шо-мырт |

## *Имена существительные с аффиксами принадлежности*

| | **ана** | **кӨймә** | **ут** | **сӨт** | **тай** | **чәй** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Единственное число** | | | | | | |
| 1 л. | ана-м | кӨймә-м | ут-ым | сӨт-ем | таем (тай-ым) | чәем (чәй-ем) |
| 2 л. | ана-ң | кӨймә-ң | ут-ың | сӨт-ең | таең (тай-ың) | чәең (чәй-ең) |
| 3 л. | ана-сы | кӨймә-се | ут-ы | сӨт-е | тае (тай-ы) | чәе (чәй-е) |
| **Множественное число** | | | | | | |
| 1 л. | ана-быз | кӨймә-без | ут-ыбыз | сӨт-ебез | таебыз (тай+ыбыз) | чәебез (чәй+ебез) |
| 2 л. | ана-гыз | кӨймә-гез | ут-ыгыз | сӨт-егез | таегыз (тай+ыгыз) | чәегез (чәй+егез) |
| | | | | | | |
| 3 л. | ана-лары | кӨймә-ләре | ут-лары | сӨт-ләре | тай-лары | чәй-ләре |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

| | **тау** | **ҮлчәҮ** | **туп** | **мәктәп** | **кунак** | **чәчәк** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Единственное число** | | | | | | |
| 1 л. | тавым | Үлчәвем | туб-ым | мәктәб- | кунаг- | чәчәг-ем |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | (тау-ым) | (ҮлчәҮ-ем) | (туп+ым) | ем (мәктәп+ем) | ым (кунак+ым) | (чәчәк+ем) |
| 2 л. | тавың (тау-ың) | Үлчәвең (ҮлчәҮ-ең) | туб-ың (туп+ың) | мәктәб-ең (мәктәп+ем) | кунаг+ың (кунак+ың) | чәчәг-ең (чәчәк+ең) |
| 3 л. | тавы (тау+ы) | Үлчәве (ҮлчәҮ+е) | туб-ы (туп+ы) | мәктәб-е (мәктәп+е) | кунаг-ы (кунак+ы) | чәчәг-е (чәчәк+е) |
| **Множественное число** | | | | | | |
| 1 л. | тавыбыз (тау+ыбыз) | Үлчәвебез (ҮлчәҮ+ебез) | туб-ыбыз (туп+ыбыз) | мәктәб-ебез (мәктәп+ебез) | кунаг-ыбыз (кунак+ыбыз) | чәчәг-ебез (чәчәк+ебез) |
| 2 л. | тавыгыз (тау+ыгыз) | Үлчәвегез (ҮлчәҮ+егез) | туб-ыгыз (туп+ыгыз) | мәктәб-егез (мәктәп+егез) | кунаг-ыгыз (кунак+ыгыз) | чәчәг-егез (чәчәк+егез) |
| 3 л. | тау-лары | ҮлчәҮ-ләре | туп-лары | мәктәп-ләре | кунак-лары | чәчәк-ләре |

## *Связь имен существительных с именем существительным (изафет)*

| I тип | II тип | III тип |
|---|---|---|
| имя + имя | имя + имя<br>(-ы/-е, -сы/-се) | имя (-ның/-нең) +<br>имя (-ы/-е, -сы/-се) |
| агач кашык | Һава флот-ы | абый-ның кита(п)б-ы |

| | | |
|---|---|---|
| тимер ишек | шәһәр транспорт-ы | әлфия-нең яулы(к)г-ы |
| алтын алка | агач тамыр-ы | абый-ның ба(у)в-ы |
| кӨмеш беләзек | китап тыш-ы | әни-нең шәл-е |
| таш кҮпер | колхоз Җир-е | әти-нең эш-е |
| калай савыт | алма тӨш-е | Татарстан-ның баш-кала-сы |
| | Казан шәһәр-е | әни-нең алка-сы |
| | Идел елгас-ы | малай-ның әни-се |
| | авыл кеше-се | |

## *Местоимения*

| № п/п | Разряды местоимений | Примеры | |
|---|---|---|---|
| 1. | Личные | мин<br>син<br>ул | без<br>сез<br>алар |
| 2. | Указатель-ные | бу<br>ул<br>алай<br>болай<br>шулай<br>тегеләй | тege<br>шушы<br>шул<br>мондый<br>шундый<br>әнә, менә |
| 3. | Определи-тельные | Үз<br>һәр<br>һәммә<br>барча | һәрбер<br>бар<br>барлык |

| № п/п | Разряды местоимений | Примеры | |
|---|---|---|---|
| 4. | Вопроси-<br>тельные | кем?<br>ни?<br>нәрсә?<br>ничек?<br>нинди?<br>нигә?<br>ничәнче?<br>ник? | нигә?<br>ни Өчен?<br>кая?<br>кайсы?<br>кайчан?<br>кайда?<br>кайдан?<br>каян? |
| 5. | Неопреде-<br>ленные | кемдер<br>нәрсәдер<br>нидер<br>ниндидер<br>ничәдер<br>ничектер<br>никтер<br>нигәдер<br>каядыр<br>кайсыдыр<br>кайчандыр<br>кайдадыр<br>кайдандыр | әллә кем<br>әллә нәрсә<br>әллә ни<br>әллә нинди<br>әллә ничә<br>әллә ничек<br>әллә ник<br>әллә нигә<br>әллә кая<br>әллә кайсы<br>әллә кайчан<br>әллә кайда<br>әллә кайдан |
| 6. | Отрица-<br>тельные | Һични<br>Һичнәрсә<br>Һичкем<br>Һичнинди<br>Һичничек<br>Һичкайчан<br>Һичкайсы<br>Һичбер<br>Һичкайдан<br>Һичкаян<br>Һичкайда | берни<br>бернәрсә<br>беркем<br>бернинди<br>берничек<br>беркайчан<br>беркайсы<br>беркая<br>беркайдан<br>беркаян<br>беркайда |

## *Падежное склонение отдельных местоимений*

| Падежи | Местоимения | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *мин* | *син* | *ул* | *Үзе* | *бу* | *шул* | *теге* |
| имени-тельный | мин | син | ул | Үзе | бу | шул | теге |
| родитель-ный | минем | синең | аның | Үзенең | моның | шуның | тегенең |
| направи-тельный | миңа | сиңа | аңа | Үзенә | моңа | шуңа | тегеңә |
| винитель-ный | мине | сине | аны | Үзен | моны | шуны | тегене |
| исходный | миннән | синнән | аннан | Үзеннән | моннан | шуннан | тегеннән |
| местно-временной | миндә | синдә | анда | Үзендә | монда | шунда | тегендә |

## *Склонение местоимения* **үз** (сам, свой) *с аффикса-ми принадлежности*

| Падежи | Местоимения | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | *Үзем* | *Үзең* | *Үзе* | *Үзебез* | *Үзегез* | *Үзләре* |
| *имени-тельный* | Үз-ем | Үз-ең | Үз-е | Үз-ебез | Үз-егез | Үз-ләре |
| *роди-тельный* | Үз-ем-нең | Үз-ең-нең | Үз-е-нең | Үз-ебез-нең | Үз-егез-нең | Үз-ләре-нең |
| *направи-тельный* | Үз-ем-ә | Үз-ең-ә | Үз-е-н-ә | Үз-ебез-гә | Үз-егез-гә | Үз-ләре-н-ә |
| *вини-тельный* | Үз-ем-не | Үз-ең-не | Үз-е-н | Үз-ебез-не | Үз-егез-не | Үз-лә-ре-н |
| *исход-ный* | Үз-ем-нән | Үз-ең-нән | Үз-е-н-нән | Үз-ебез-дән | Үз-егез-дән | Үз-ләре-н-нән |
| *местно-времен-ной* | Үз-ем-дә | Үз-ең-дә | Үз-е-н-дә | Үз-ебез-дә | Үз-егез-дә | Үз-ләре-н-дә |

## *Обычный порядок слов в повествовательном предложении*

| Обстоятельства времени и места | Группа подлежащего (с определением) | Группа сказуемого (дополнения, обстоятельства) | Сказуемое |
|---|---|---|---|
| БерсекӨнгә мәктәптә | спорт бәйрәме | сәгать дҮрттә | башлана. |

## *Обычный порядок слов в вопросительном предложении*

I.

| Обстоятельства времени и места | Группа подлежащего (с определением) | Вопросительное местоимение | Сказуемое |
|---|---|---|---|
| Иртәгә безнең сыйныф бҮлмәсендә | математика олимпиадасы | ничәдә | башлана? |

II.

| Обстоятельства времени и места | Группа подлежащего (с определением) | Группа сказуемого (дополнения, обстоятельства) | Сказуемое с аффиксами вопроса -мы/-ме? |
|---|---|---|---|
| БҮген Актлар | чыгарылыш | сәгать Җидедә | башланамы? |

| | | | |
|---|---|---|---|
| залында | кичәсе | | |
| | | | |

## Тематические группы глаголов

| Глаголы движения | Глаголы действия | Глаголы процесса | Глаголы состояния | Глаголы отношения | Глаголы поведения | Глаголы звучания | Глаголы речи | Глаголы мышления | Глаголы чувствительного восприятия | Образоподражания |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бар- | казы- | Өй- | чирлә- | хӨрмәт ит- | мактан- | яңгыра- | сӨйлә- | фикерлә- | кҮр- | елкылда- |
| кер- | ур- | кайна- | авыр- | хыянәт ит- | хәйләлә- | шаула- | әйт- | уйла- | сиз- | Җемелдә- |
| кҮч- | тура- | агар- | йокла- | ихтирам ит- | әшәкелән- | чылтыра- | тиргә- | аңла- | ишет- | бҮлтәй- |
| кҮтәрел- | чәч- | дымлан- | туң- | яманла- | мәсхәрәлә- | челтерә- | әрлә- | тӨшен- | той- | ялт-йолт кил- |
| тӨш- | ю- | юкар- | шаккат- | макта- | ерткычлан- | дыңгырда- | ялганла- | сана- | сиземлә- | дер-дер калтыра- |
| чык- | яр- | суын- | курык- | хурла- | | гӨрселдә- | сора- | бел- | | Җем-Җем ит- |
| юнал- | тек- | кыюлан- | сабыр ит- | | | мӨгрә- | дәш- | таны- | | |
| бат- | Җиң- | акыллылан- | шатлан- | | | кешнә- | эндәш- | | | |
| атла- | берләш- | яшәр- | кайгыр- | | | сайра- | бәхәсләш- | | | |
| йӨгер- | дәвала- | картай- | сагын- | | | Өр- | Җавап бир- | | | |
| йӨз- | укы- | тундыр- | | | | Үкер- | сора- | | | |
| чап- | | яктыр- | | | | акыр- | белеш- | | | |
| юрт- | | Җиллә- | | | | бакыр- | килеш- | | | |
| Үрмәлә- | | караңгылан- | | | | шартла- | боер- | | | |
| ак- | | | | | | чыңла- | куш- | | | |
| хәрәкәт ит- | | | | | | | Үгетлә- | | | |
| | | | | | | | сәламлә- | | | |

# *Формы времен изъявительного наклонения*

| Настоящее | Прошедшее категорическое | Прошедшее результативное | Прошедшее незаконченное | Прежде прошедшее | Прошедшее многократное | Будущее неопределенное | Будущее категорическое время | Будущее в прошедшем |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **-а/-ә<br>-ый/-и** | **-ды/-де<br>-ты/-те** | **-кан/-кән<br>-ган/-гән** | **-а иде/-ә иде<br>-ый иде/-и иде** | **-кан иде/-кән иде<br>-ган иде/-гән иде** | **-а торган иде/-ә торган иде<br>-ый торган иде/-и торган иде** | **-ыр/-ер<br>-ар/-әр/-р** | **-ачак/-әчәк<br>-ячак/-ячәк** | **-ачак иде/-әчәк иде<br>-ячак иде/- ячәк иде** |
| бара | бар-ды | бар-ган | бар-а иде | бар-ган иде | бар-а торган иде | бар-ыр | бар-ачак | бар-ачак иде |
| әйтә | әйт-те | әйт-кән | әйт-ә иде | әйт-кән иде | әйт-ә торган иде | әйт-ер | әйт-әчәк | әйт-әчәк иде |
| укый | укы-ды | укы-ган | ук(ы)-ый иде | укы-ган иде | ук(ы)-ый торган иде | укы-р | укы-ячак | укы-ячак иде |
| сӨйли | сӨйлә-де | сӨйлә-гән | сӨйл(ә)-и иде | сӨйлә-гән иде | сӨйл(ә)-и торган иде | сӨйлә-р | сӨйлә-ячәк | сӨйлә-ячәк иде |
| кайта | кайт-ты | кайт-кан | кайт-а иде | кайт-кан иде | кайт-а торган иде | кайт-ыр | кайт-ачак | кайт-ачак иде |
| | | | | | | яз-ар | | |
| | | | | | | кӨт-әр | | |

# *Спряжение желательного наклонения по лицам и числам*

| | | Утвердительная форма | | Отрицательная форма | |
|---|---|---|---|---|---|
| Число | Лицо | твердый вариант | мягкий вариант | твердый вариант | мягкий вариант |
| Единственное | I | бар-**ый-м** | кил-**и-м** | бар-**м-ый-м** | кил-**м-и-м** |
| Множественное | I | бар-**ый-к** | кил-**и-к** | бар-**м-ый-к** | кил-**м-и-к** |

## *Времена глаголов изъявительного наклонения*

| Названия времен | Показатели |
|---|---|
| Настоящее время | -а/-ә, -ый/-и |
| Прошедшее категорическое время | -ды/-де, -ты/-те |
| Прошедшее результативное время | -кан/-кән, -ган/-гән |
| Прошедшее незаконченное время | -а иде/-ә иде, -ый/-и иде |
| Давнопрошедшее время | -ган иде/-гән иде, -кан иде/-кән иде |
| Прошедшее многократное время | -а торган иде/-ә торган иде, -ый торган/-и торган иде |
| Будущее неопределенное время | -ыр/-ер, -ар/-әр, -р |
| Будущее категорическое время | -ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк |
| Будущее-прошедшее время | -ачак иде/-әчәк иде, -ячак иде/-ячәк иде |

## *Неличные формы глагола*

| Деепричастие | Причастие | | Имя действия | Инфинитив |
|---|---|---|---|---|
| **1. -ып/-еп/-п** | **1. -учы/-Үче** | **4. -ачак/-әчәк** | **-у/-Ү** | **-рга/-ргә** |
| | | **-ячак/-ячәк** | | **-ырга/-ергә** |
| **2. -кач/-кәч** | **2. -а торган /** | | | **-арга/-әргә** |
| **-гач/-гәч** | **-ә торган** | **5. -ыр/-ер/-р** | | |
| | **-ый торган /** | **-ар/-әр** | | |
| **3. -а/-ә** | **-и торган** | | | |
| **-ый/-и** | | | | |
| | **3. -кан/-кән** | | | |
| **4. -канчы/-кәнче** | **-ган/-гән** | | | |
| **-ганчы/-гәнче** | | | | |
| | | | | |
| 1. бар-ып | 1. бар-учы | кер-Үче | | |
| кер-еп | сайла-учы | сӨйлә-Үче | бар-у | сайла-рга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| сайла-п | | | | |
| сӨйлә-п | 2. бар-а торган | кер-ә торган | сӨйлә-Ү | сӨйлә-ргә |
| | сайл-ый торган | сӨйл-и торган | | |
| 2. кайт-кач | | | кер-Ү | бар-ырга |
| кит-кәч | 3. кайт-кан | кит-кән | | |
| бар-гач | бар-ган | кил-гән | сайла-у | кер-ергә |
| сайла-гач | сайла-ган | сӨйлә-гән | | |
| сӨйлә-гәч | | | кӨл-Ү | яз-арга |
| | | | | |
| 3. бара-бара | 4. бара-чак | килә-чәк | әйт-Ү | кит-әргә |
| керә-керә | кайт-ачак | кер-әчәк | | |
| сайлый-сайлый | сайла-ячак | сӨйлә-ячәк | кит-Ү | |
| сӨйли-сӨйли | | | | |
| | | | | |
| 4. бар-ганчы | 5. бар-ыр | кер-ер | | |
| сӨйлә-гәнче | яз-ар | кӨт-әр | | |
| кайт-канчы | сайла-р | сӨйлә-р | | |
| кит-кәнче | | | | |

## *Залоги*

| Залог | Значение | Аффиксы | Примеры |
|---|---|---|---|
| Основной | действие производится субъектом (грамматическим подлежащим) | нулевая форма | (ул) бара, (ул) әйтә |
| Возвратный | действие возвращается к субъекту | -ын/-ен, -н | (ул) ю-**ын-а**, (ул) ки-**ен-ә** |
| Страдательный | действие производится объектом (грамматическим подлежащим) | -ыл/-ел,-л; -ын/-ен, -н | ю-**ыл-а**, ки-**ел-ә**, башла-**н-а** |
| Взаимо-совместный | действие производится несколькими субъектами | -ыш/-еш, -ш | ю-**ыш-а**, бир-**еш-ә**, эшлә-**ш-ә** |
| Понудительный | действие производится | -дыр/-дер, -тыр/-тер, -т | яз-**дыр**, әйт-**тер**, сӨйлә-**т**, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | грамматическим дополнением | -ар/-әр, -ыр/-ер, -кыр/-кер, -гыр/-гер, -гыз/-гез, -каз/-кәз, -кыз/-кез, -сәт, -ыз/-ез | кайт-**ар**, ят-**кыр**, мен-**гер**, тер-**гез**, ят-**кыз**, кҮр-**сәт**, там-**ыз** |

## ***Порядок добавления аффиксов к глагольному корню***

| | | | | | | | Формирующие аффиксы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Глагол | Корень | Словообразовательный аффикс | залог | аффикс повторяемости действи | аффикс отрицания | аффикс наклонения | причастие, деепричастие, имя действия, инфинитив | время | лицо, число | Вспомогательный глагол |
| эшләт мәссез | эш | -лә | -т | —— | -мә | —— | —— | -с | -сез | —— |
| баргалаасалар | бар | —— | —— | -гала | —— | -са | —— | —— | -лар | —— |
| эшләтте-рергә | эш | -лә | -, -тер | —— | —— | —— | -ергә | —— | —— | —— |
| бара торган | бар | —— | —— | —— | —— | —— | -а торган | —— | —— | —— |
| кайта тордылар | кайт | —— | —— | —— | —— | —— | -а | —— | —— | торды-лар |
| кайтарткаламагач | кайт | —— | -ар, -т | -кала | -ма | —— | -гач | —— | —— | —— |
| эшләм | эш | -лә | —— | —— | -мә | —— | —— | -ячәк | -без | —— |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ә-ячәкбез | | | | | | | | | | |
| иялəштерY | ия | -ләш | -тер | —— | —— | —— | -Y | —— | —— | —— |
| аңлатыр-быз | аң | -ла | -т | —— | —— | —— | —— | -ыр | -быз | —— |
| сӨйләшсәк | сӨйлә | —— | -ш | —— | —— | -сә | —— | —— | -к | —— |
| ясаш-тыр-гала-мыйча | яса | —— | -ш, -тыр | -гала | -м | —— | -ыйча | —— | —— | —— |

## *Разряды имен числительных*

| Количественное числительное | Порядковое числительное | Разделительное числительное | Приблизительное числительное | Собирательное числительное |
|---|---|---|---|---|
| бер | бер-енче | бер-әр | —— | бер-әY |
| ике | ике-нче | ике-шәр | ике-ләп (бер-ике) | ик(е)-әY |
| Өч | Өч-енче | Өч-әр | Өч-ләп (ике-Өч) | Өч-әY |
| алты | алты-нчы | алты-шар | алты-лап (биш-алты) | алт(ы)-ау |
| ун | ун-ынчы | ун-ар | ун-лап (ту-гыз-ун) | ун-ау |
| илле | илле-нче | илле-шәр | илле-ләп (илле-алтмыш) | —— |

## *Разряды наречий*

| Наречия образа действия | Наречия меры и степени | Наречия места | Наречия времени | Наречия причины и цели | Наречия сравнения |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| тиз | бик | ерак | хәзер | юри | кӨмештәй |
| аягҮрә | шактый | якын | иртәгә | юкка | мамыктай |
| әкрен | аз | югары | бҮген | бушка | яшьләрчә |
| яланаяк | бераз | тҮбән | кичә | әрәмгә | корычтай |
| тын | кҮп | янәшә | кӨндез | тиккә | картларча |
| ашык-пошык | озак | рәттән | быел | заяга | китапча |
| кинәт | байтак | аста | былтыр | тикмәгә | |
| тора-бара | бӨтенләй | өстә | бераздан | тиктомалга | |
| ҖәяҮ | тулаем | монда | тиздән | | |
| бертавыштан | тулысынча | биредә | кышын | | |
| Өзлексез | Өлешчә | анда | Җәен | | |
| искәрмәстән | | | кӨзен | | |
| тӨрлечә | | | язын | | |
| бергә | | | иртән | | |
| берьюлы | | | кичен | | |
| ӨчәҮләп | | | элек | | |

## *Классификаци частиц по значению*

| Указа-тельные | Определи-тельно-уточни-тельные | Ограничи-тельно-выделитель-ные | Отрица-тельные | Вопроси-тельные | Модальные | Экспрессив-но-эмоциональ-ные |
|---|---|---|---|---|---|---|
| әнә<br>менә | нәкъ | бары<br>бары тик<br><br>гына/генә, кына/кенә<br>фәкать | Һич<br>тҮгел | -мы/-ме<br>әллә<br><br>-мыни/-мени<br><br>соң | әллә<br>-дыр/-дер, -тыр/-тер | бик<br>бит<br><br>да/дә, та/тә<br><br>әле<br>инде<br>ич<br>иң<br>ла/лә<br>лабаса/ләбаса<br>-сана/-сәнә<br>ук/Үк<br>хәтта<br>-чы/-че |

## *Правописание частиц*

| Частицы, которые пишутся перед словом | | Частицы, которые пишутся после слова | | Частицы, которые пишутся до и после слова | |
|---|---|---|---|---|---|
| через дефис | раздельно | слитно | раздельно | слитно | раздельно |
| **Өр**-яңа | **иң** зур | **Һич**нинди | белми **тҮгел** | белми**ни** | бир **әле** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **чем**-кара | **нәкъ** Үзе | **һич**кайчан | ул **гына** | беләсеңме | **әле** китмәде |
| **ямь**-яшел | **Җете** кызыл | **һич**бер | китап **кына** | кил**сәнә** | әйттеләр **әллә** |
| **кып**-кызыл | **тома** сукыр | **һич**кем | син **дә** | кайт**сана** | **әллә** кайт-тылар |
| **кҮм**-кҮк | **иң** матур | **һич**нәрсә | гел **генә** | кайттың**мы** | **инде** килде |
| | **бик** сӨйкемле | | белә **бит** | кҮрмәдең**ме ни** | килде **инде** |
| | | | бас **кына** | язган**дыр** | |
| | | | әйт **инде** | кил**че** | |
| | | | кил **әле** | матур**дыр** | |
| | | | әйткәч **Үк** | | |
| | | | беләләр **ич** | | |
| | | | утыра **ич** | | |

## *Классификация союзов и союзных слов*

| Сочинительные | | | Подчинительные |
|---|---|---|---|
| соединительные | разделительные | Противительные | |
| һәм<br>вә<br>да/дә<br>та/тә<br>тагын<br>тагы<br>ни...ни<br>янә | я<br>яки<br>яисә<br>әле...әле | ә<br>әмма<br>ләкин<br>тик<br>исә<br>фәкать<br>бары<br>мәгәр<br>хәлбуки | чӨнки<br>ки<br>гҮя<br>гҮяки<br>әгәр<br>хәтта<br>әйтерсең<br>диярсең<br>гәрчә<br>я»ни<br>аеруча<br>бигрәк тә |

Местоименно-соотносительные слова

| В придаточном предложении | В главном предложении | | В придаточном предложении | В главном предложении |
|---|---|---|---|---|
| кемнең<br>кемне | шуның<br>шул | | кҮпме<br>кҮпме | шулкадәр<br>шулхәтле |

| | |
|---|---|
| кемнең | щул |
| кемнән | шул |
| кемдә | шул |
| кемгә | шул |
| кем | шуның |
| кем | шул |
| кем | шуны |
| кем | шунда |
| кемнең | шуннан |
| кемнең | шунда |
| кемне | шуны |
| кемне | шуңа |
| кемне | шуның |
| кемне | шунда |
| кемнән | шуннан |
| кемнән | шуны |
| кемгә | шуңа |
| кемгә | шуның |
| кемгә | шунда |
| кайсы | шунда |
| кайдагы | шундагы |
| кайдагы | шул |
| ни | шул |

| | |
|---|---|
| кҮпме | бӨтенесе |
| кҮпме | барысы |
| кҮпме | шулчаклы |
| кайда | шунда |
| кайдан | шуннан |
| никадәр | шул кадәр |
| ничаклы | шул чаклы |
| кҮпме | шул кадәрле |
| кая | шунда |
| кайсы | шундагы |
| нинди | шуңа карап |
| кҮпме | шул дәрәҖәдә |
| ничек | шулай |
| ничек | шундый |
| нинди | шулай |
| ни | шуны |
| ни | Һәммәсен |
| кай вакыт | шул вакыт |
| кай урын | шул урын |
| кем Өчен | шуның Өчен |
| кем | аның |
| кемдә | анда |
| кемдәге | андагы... |

**Друзья!**

Если вам захочется дальше изучать татарский язык, вы сможете обратиться и к другим изданиям.

# ثитература

(әдәбият)


Асадуллин А.Ш. Учимся говорить, читать и писать по-татарски. — Казань: Магариф, 1993. — 152 с.

Асадуллин А.Ш., Асадуллин Ф.А. Ключ к языку (Тел ачкычы): Русско-татарско-английский картинный словарь. — Казань: Магариф, 1996. — 200 с.

Бадиков К.Г. Уроки татарского языка. Самоучитель. — Казань, 1993.

Габдулхаков В.Ф. Современная языковая коммуникация и технология развития речевой деятельности в условиях билингвизма. — Казань: Хәтер, 1998. — 207 с.

Газеев А.А. Обучение татарскому языку русскоязычных школьников и взрослого населения. Учебно-методическое пособие. — Казань: Таң—Заря, 1997. — 180 с.

Газизов Р.С. Татарский язык (дял самостоятельно изучающих). — Казань: Таткнигоиздат, 1960. — 252 с.

Ибрагимов Т. Ускоренное обучение татарскому языку. — Казань: КГУ, 1993. — 122 с.

Курбангалиев М., Газизов Р. Систематическая грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка. — Казань: Татиздат, 1932. — 171 с.

Литвинов И.Л. Я начинаю говорить по-татарски. — Казань, 1994. — 319 с.

Сабирова Г.С., Сабиров Р.А. ثурс самоучителя татарского языка. حауч. ред. — проô. Саôиуллина Ф.С. — Альметевск, 200. — 345 с.

Салехова Н.Х., Максимова А.К., Харисова Ч.М. Интенсивное обучение татарскому языку (Практический курс). — Казань: Магариф, 1993. — 128 с.

Сафиуллина Ф.С. Базовый татарско-русский и русско-татарский словарь для школьников. — Казань: Хәтер, 1997 . — 64 б.

Сафиуллина Ф.С., Фатхуллова К.С. Татар теленнән тестлар һәм кроссвордлар. — Казань: Хәтер, 1998. — 94 б.

Сафиуллина Ф.С., Галиуллин К.Р. Русско-татарский разговорник. — Казань: Тат.кн.изд-во, 1986. — 304 с.

Сафиуллина Ф.С., Галиуллин К.Р. Тематический русско-татарский словарь. — Казань: Тат.кн.изд-во, 1989. — 288 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарский язык. Самоучитель. — Казань: Таткнигоиздат, 1991. — 445 с.

Сафиуллина Ф.С., Юсупова А.Ш. Изучаем татарский язык: Пособие для начинающих. — Казань: Союз журналистов ТССР, 1991. — 122 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарский язык в диалогах. — Казань: Магариф, 1994. — 221 с.

Сафиуллина Ф.С. Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь. — Казань: Татр.кн.изд-во, 1996. — 285 с.

Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татарча-русча антонимнар сҮзлеге. — Казан: Хәтер, 1997. — 96 б.

Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленеٳ омонимнар сҮзлеге. — Казан: Хәтер, 1997. — 96 б.

Сафиуллина Ф.С., Фатхуллова К.С. и др. Татарский язык. Интенсивный курс. — Казань: Хәтер, 1998. — 272 с.

Сафиуллина Ф.С., Фатхуллова К.С. Татарский язык. Интенсивный курс. — Казань: Хәтер, 1999. — 448 с.

Сафиуллина Ф.С., Фатхуллова К.С. ژатар теленә өйрәтү («Татарский язык. Интенсивный курс». (Казань: Хәтер, 1998, 1999.) китабы белән ٲләүче укыиучылар өчен методик кулланма). — تазан: صәтер, 1999. — 96 с.

Сафиуллина Ф.С., Шарафиева Г.Р. Учат таблица и схемы. — Казань: Магариф, 1998. — 96 с.

Сафиуллина Ф.С. Татарско-русский иллюстрированный словарь для малышей. — Казань: Заман, 1998. — 151 с.

Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сҮзлеге. — Казан: Хәтер, 1997. — 256 б.

Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Мой первый татарский словарь: Иллюстрированный татарско-русский словарь. — Казань: Магариф, 1995. — 160 с.

Внимание!!! При окончательном варианте **правильно** проставить страницы!

## Содержание


| | |
|---|---|
| От автора | |
| *Урок первый.* | Особенности татарского языка. |
| *Урок второй.* | Фонетические особенности татарского языка (гласные звуки). |
| *Урок третий.* | Как спросить? |
| *Урок четвертый.* | Согласные звуки в татарском языке. |
| | Утверждение и отрицание. Диалоги. |
| *Урок пятый.* | Особенности слогоделения. |
| | Ударение. |
| | Множественное число существительных. |
| | О средствах, выражающих принадлежность. |
| | Диалоги. Задания. |
| *Урок шестой.* | Некоторые графические правила татарского языка. |
| | Цвета. |
| | Принадлежность (множественное число). |
| | Числительное. Порядковые числительные. |
| *Урок седьмой.* | Как узнать время? Диалоги. |
| | О падежах. |
| | Части тела человека. |
| | Родительный падеж. |
| | Местно-временной падеж. |
| | О семье. Диалоги. Задания. |
| *Урок восьмой.* | Повторение пройденного. Обобщающий урок. |
| | О доме и квартире. |
| | Тюрко-татарские заимствования в русском языке. |

| | |
|---|---|
| | Диалоги. Задания. |
| *Урок девятый.* | Глагол.<br>Желательное наклонение.<br>Повелительное наклонение.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок десятый.* | Приветствия.<br>Направительный падеж.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок одиннадцатый.* | Времена глаголов.<br>Настоящее время.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок двенадцатый.* | Винительный падеж. Диалоги.<br>Указательные местоимения в различных падежах.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок тринадцатый.* | Исходный падеж.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок четырнадцатый.* | Прилагательные. Диалоги.<br>Степени прилагательных (сравнительная, превосходная).<br>Диалоги. |
| *Урок пятнадцатый.* | Школа.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок шестнадцатый.* | Продукты питания. Овощи и фрукты. Рынок. Диалоги. |
| *Урок семнадцатый.* | Повторение прошедшего урока.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок восемнадцатый.* | Прошедшее категорическое время.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок девятнадцатый.* | Деньги. Рынок. Магазины.<br>Диалоги. |
| *Урок двадцатый.* | Повторение пройденного. Прошедшее неочевидное (неопределенное) время.<br>Диалоги.<br>Который час? Диалоги. Задания.<br>Время. Диалоги. |

| | |
|---|---|
| | Сколько Вам (тебе) лет? |
| *Урок двадцать первый.* | Времена года.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок двадцать второй.* | Незавершенное прошедшее время.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок двадцать третий.* | Стереотипы общения.<br>Диалоги. |
| *Урок двадцать четвертый.* | Книга. Печать.<br>Конструкция -ган/-гђн, -кан/-кђн + аффиксы принадлежности + бар (юк). Диалоги. Задания. |
| *Урок двадцать пятый.* | Давнопрошедшее время.<br>Задания. |
| *Урок двадцать шестой.* | Татарская кухня.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок двадцать седьмой.* | Повторяемое прошедшее время.<br>Диалоги. Задания.<br>Дикие птицы. |
| *Урок двадцать восьмой.* | Образование.<br>Профессии.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок двадцать девятый.* | Одежда.<br>Обувь.<br>Украшения.<br>Диалоги.<br>Указательные местоимения.<br>Диалоги. |
| *Урок тридцатый.* | Дни недели.<br>Диалоги.<br>Будущее время.<br>Задания. |
| *Урок тридцать первый.* | Будущее в прошедшем.<br>Диалоги.<br>Отрицательная форма глаголов будущего времени.<br>Задание. |
| *Урок тридцать второй.* | Употребление послелогов. |

| | |
|---|---|
| | Диалоги. |
| *Урок тридцать третий.* | Послелоги (продолжение).<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок тридцать четвертый.* | Повторение пройденного материала.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок тридцать пятый.* | Послеложные слова.<br>Диалоги. Задания. |
| *Урок тридцать шестой.* | Частицы.<br>Диалоги. |
| *Урок тридцать седьмой.* | Частицы (продолжение).<br>Диалоги. |
| *Урок тридцать восьмой.* | Выражение условия.<br>Диалоги.<br>Народные приметы. |
| *Урок тридцать девятый.* | Разговор по телефону.<br>Задания. |
| *Урок сороковой.* | Выражение временных отношений.<br>Диалоги. |
| *Урок сорок первый.* | Как выразить желание?<br>Диалоги. |
| *Урок сорок второй.* | Возможно или невозможно?<br>Диалоги.<br>Переводим. |
| *Урок сорок третий.* | Парные слова.<br>Диалоги. |
| *Урок сорок четвертый.* | Выражение пространственных отношений.<br>Диалоги. Задания. |
| Урок сорок пятый. | Тюрко-татарские заимствования в русском языке (беседа со специалистом). |
| *Урок сорок шестой.* | Глаголы в татарской речи.<br>Задания. |
| *Урок сорок седьмой.* | Глаголы в татарской речи (продолжение).<br>Диалоги. Задания. |

| | |
|---|---|
| *Урок сорок восьмой.* | Транспорт.<br>Почта. Телефон. Телеграф.<br>Диалоги.<br>Отдых. Диалоги.<br>Печать. Диалоги.<br>Здоровье. Диалоги. |
| *Урок сорок девятый.* | Повторение и обобщение пройденного.<br>Работа по текстам. |
| *Урок пятидесятый.* | Вводные слова.<br>Диалоги. |
| *Урок пятьдесят первый* | Обобщение пройденного материала.<br>Н.Нђќми. Татар теле. |
| *Приложение 1.*<br>*(Кушымта).* | Г.Бђширов. Мђзђклђр.<br>Ш.Галиев. Хикмђтле сњзлђр.<br>Татар поэзиясеннђн њрнђклђр.<br>Текстлар. |
| *Приложение 2.* | Таблицы. |
| *Литература.* | |
| *Содержание.* | |